ДОЛЛАР ҮСКӘНДӘ...

Белгечләр кыйммәтле әйберләр алырга киңәш итми

> 5

10 ЕЛ ҮТКӘЧ

Универсиада безне ничек үзгәртте?

> 16

РАЯЗ ФАСЫЙХОВ:

«Җыр ул – тарих»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 99 (29066) | Җомга | 14 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Чулпан Гарифуллина фотолары / Рөстәм Миңнуллин коллажы

СҮНМӘСЕН ЙОЛДЫЗ!

«ВТ» ХӘБӘРЧЕСЕ ЯНГЫННАН СОҢ ТОРГЫЗЫЛА БАШЛАГАН ТАТАР АВЫЛЫНДА БУЛЫП КАЙТТЫ

Курган өлкәсендәге Йолдыз (Эчкен) авылының яңадан яшәргә өйрәнеп килгән мәле. Мәгълүм булганча, 7 май төнендә биредә көчле янгын чыгып, авылны көлгә әйләндерә. Ялкын теле озын була шул. Сәгать ярым вакыт эчендә 200дән артык хуҗалыкны ут камап ала. 377 хуҗалыкның нибары 90ы гына төзек кала. Ут мәчеткә һәм мәктәпкә тими. Иң аянычы – фаҗига 7 кешенең гомерен өзә. Бүген авыл ни хәлдә? Андагы халык нинди өмет белән яши? «ВТ» хәбәрчесе Йолдызның бүгенгесе белән танышып кайтты.

> 6–7

Ишетми калмагыз

Оборона министрлыгы Кораллы көчләр белән контракт төзүгә комачаулаган чирләр исемлеген әзерләгән. Хокукый актлар проектлары порталына урнаштырылган исемлеккә барлыгы 26 чир кертелгән. Анда ВИЧ, уртача авырлыктагы бронхиаль астма, B һәм C гепатиты, туберкулез, эпилепсия, I типтагы шикәр чире, яман шешнең кайбер төрләре күрсәтелгән.

Моннан тыш йөрәк авыруларыннан (йөрәкнең җиткелекле эшләмәвенә китергән), II стадиядәге гипертониядән, психик һәм башка җитди авырулардан интегүчеләр контракт буенча хезмәт итә алмаячак.

Исегезгә төшерәбез: июнь ахырында хөкем ителүчеләрне һәм хәрби хезмәткә яраклылыгы чикләнгән кешеләрне хезмәткә алуны рөхсәт иткән закон кабул ителде. Анда әйтелгәнчә, яраклылыгы чикләнеп тә, Оборона министрлыгы раслаган исемлектәге чирләргә ия булмаучылар контракт төзи алачак.

12 июль мәгълүматлары буенча, Казандагы 5 комлыкның өчесе гигиена таләпләренә туры килми. Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе хәбәренә караганда, ике комлык – «Нижнее Заречье» һәм «Локомотив» комлыгы тирәсендәге су микробиологик, химик күрсәткечләре буенча таләпләргә җавап бирми. «Аккош күле» комлыгы исә химик күрсәткечләр буенча гына нормативка сыешмый.

Республикада паразит һәм вируслар буенча нормативларга туры килмәгән комлыклар ачыкланмаган. Мамадыш һәм Лениногорск пляжлары – микробиологик, Лаешныкы химик күрсәткечләре буенча таләпләргә җавап бирми.

Быел республикада яшүсмерләр арасында менингококк инфекциясе йоктыруның берничә очрагы булган. Роспотребнадзорның Татарстандагы идарәсе матбугат хезмәтеннән «Татар-информ» хәбәрчесенә сөйләп үтелгәнчә, Чаллыда һәм Питрәч районында берәр кеше чирләгән. Яшел Үзән районында чир йоктыруның 2 очрагы теркәлгән. Казанда яшүсмерләр арасында мондый очраклар юк.

Исегезгә төшерәбез: шушы көннәрдә генә Екатеринбургта 15 кешенең менингококк йоктыруы ачыкланган. 2 кеше вафат булган. Республика ведомствосында басым ясап әйтелгәнчә, Татарстанда яшүсмерләр Свердловск өлкәсендә чирләүчеләр белән элемтәдә тормаган.

Теманың дәвамы 9 нчы биттә >

Ял көннәрендә Татарстанда +26 градуска кадәр җылытачак. Киләсе атна башында көндез һава температурасы +24 градустан артмаячак.

Гидрометеоүзәк мәгълүматлары буенча, 15, 16 июль – шимбә һәм якшәмбедә көндез термометрның терекөмеш баганасы +20...+26 градус күрсәтәчәк. Төнлә +11...+16. Урыны белән кыска вакытлы яңгырлар көтелә.

Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, дүшәмбе һәм сишәмбе – 17, 18 июльдә көндез һава температурасы +19...+24 градус чикләрендә тирбәләчәк. Урыны белән яңгырлар булырга мөмкин.

Районнарда ни хәлләр?

Минзәлә

Моннан 3 ел элек Аю авылында ике катлы яңа мәчет төзелә башлады. Авыл имам-хатыйбы Рәфкать хәзрәт Ялалов тырышлыгы, битараф булмаган авылдашлар, мөселманнар ярдәме белән әлеге эш, ниһаять, ахырына якынлаша. Шушы көннәрдә манарага ай куелды. Күптән көтелгән чарага авыл халкы, кайткан кунаклар җыелды. Ярымайны 18 метр биеклеккә күтәреп кую эшендә ПМК «Мелиорация» оешмасы булышты. Әлеге эшне «Ивановец» автокранында Василий Табанаков башкарды. Казан шәһәрендә ясатып кайтарылган ярымай өскә күтәрелгән һәм урнаштырылган мизгелләрдә мөселманнар тәкбир әйтеп тордылар.
(«Минзәлә-информ»)

Кукмара

Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көнендә Кукмарада игезәкләр парады узды. «Икеләтә шатлык» дип аталган бәйрәмгә 30га якын пар игезәк җыелды. «Иң кечкенә игезәкләргә – нибары сигез ай, ә иң олыларына 35 яшь иде. Бу парад соңгысы түгел, киләчәктә тагын да күбрәк катнашучыларны җәлеп итәргә планлаштырабыз», – ди районның ЗАГС бүлеге җитәкчесе Зөлфия Латыйпова. Катнашучылар бу чарага Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы хөрмәтенә милли костюмнар киеп килгән.
(«Хезмәт даны»)

Апас

Быел Әдәби Сабан туе Апас җирлегендә узачак. 11 августта үткәреләчәк чарага Татарстанның төрле районнарыннан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән быел да меңнән артык кунак килер дип көтелә. Әдәби Сабан туе программасында, Әдәби марафон проекты финалистларын бүләкләү белән бергә, Әдәби көрәш, милли Сабан туе уеннары, танылган җырчылар һәм артистлар белән концерт программасы, танылган язучылар белән очрашулар һәм автограф-сессияләр һ.б. бар. Сабан туе ахырында кунаклар өчен Апас районы музейларына һәм китапханәләренә экскурсияләр дә оештырылачак.
(tat-i.net)

Арча

Үзәк мәчет каршында «Дини йола» үзәге төзи башладылар. Аның нигезенә беренче таш салыну тантанасында Арча районы башлыгы Илшат Нуриев, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев катнашты. Яңа сафка басачак бина беренче чиратта балаларны, үсеп килүче буынны дини кануннар нигезендә тәрбияләү мөмкинлекләрен үстерергә ярдәм итәчәк. Бирегә дини юнәлештәге мөселман балалар бакчасы ачу планлаштырыла. Әлеге бакчаның эшчәнлеге гадәти бакчадан хәләл ризык булуы, балаларга дини-әхлакый тәрбия бирелүе белән аерылып торачак. Бина ике катлы булачак, гомуми мәйданы – 800 квадрат метр. Балалар бакчасы 20 балага исәпләнгән. Бинаны 2024 елда кулланылышка тапшыру көтелә.
(dumrt.ru)

ЧИТКӘ ЙӨРИСЕ ТҮГЕЛ

Ерактагы диңгез кирәкми. Татарстан Рәисе эшмәкәрләр белән шәһәр яны ял итү урыннарын үстерү турында фикер алышты.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, республикада туризм тармагын үстерү өчен шартлар тудырыла. Табигать һәм шәһәр яны туризмы да үсә.

– Күп проектлар тормышка ашырыла, һәрберсенең үз өстенлеге бар. Безгә әчке туризмны үстерергә кирәк. Бүген Татарстаннан китмичә генә елга буенда яки урманда яхшы итеп ял итү мөмкинлеге бар. Безнең Зәңгәр күлләр, Кама, Идел, Нократ елгалары кебек кабатланмас урыннарыбыз бар. Мөмкинлекләр бик зур. Моның өчен шартлар тудырыла. Иң мөһиме – бу эш белән шөгыльләнергә теләгән кешеләр, эшмәкәрләр бар. Әмма бу эшне экологлар һәм урманчылар белән берлектә алып барырга кирәк, – диде Татарстан Рәисе.

«Татарстан шәһәрләрен үстерү институты» фондының табигый территорияләр буенча департаменты җитәкчесе Оксана Саргина сүзләренә караганда, республикада шәһәр яны туризмына 3,3 миллиард сум күләмендә инвестиция салынган. Татарстанда 16 районда 42 объект эшли, 450 эш урыны булдырылган. 2022–2023 елларда аларда 80 мең кеше ял иткән. Өч елда тагын 2,6 миллиард сум акча тотып, 9 районда тагын 14 объект ачарга ниятлиләр.

Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе Сергей Иванов әйтүенчә, «Туризм һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проекты кысасында узучы федераль грант бәйгеләре аша узган ел 18 табигать ял итү объекты 271 миллион сум акча алган. 220 миллион сумны Мәскәүдән алганнар. Моннан тыш, тагын 16 миллион сумны җиһазлар һәм инвентарь алу, ял итү урыннарын тәртипкә салу өчен тотканнар. Быел тагын ярдәм булачак.

tatarstan.ru

Очрашуда бизнес әһелләре Яшел Үзән, Питрәч, Спас, Биектау һәм Менделеевск районнарында урнашкан үз проектларын тәкъдим итте. Очрашу узган «Утрау» комплексы 2021 елда Яшел Үзән районында ачылды. Бирегә 52 торак модуле, мунча комплексын үз эченә алган SPA-үзәк, бассейн, ресторан һәм башка ял итү мөмкинлекләре бар.

Ә СУДЬЯЛАР КЕМ?

Дәүләт Советында

Александр Грибоедовның «Горе от ума» комедиясе герое Александр Чацкий монологындагы бу сүзләр, бәлки, язмам исеменә бик үк килешле дә түгелдер. Ул әлеге сүзләрне үзе гөнаһлы була торып, кешеләрне хөкем итәргә яратучылар тарафына әйткән. Мин исә Татарстанда Конституция суды бетерелеп, аның урынына Конституция Советы оештыру уңаеннан язам. Шулай итеп, судьялар бетте, алар урынына әгъзалар калды. Күңелгә бераз утырым да калды әле, хакимият вертикален ныгытам дип, ул хәтле үк кылану кирәк микән?

Шулай итеп, 13 июльдә узган Дәүсовет утырышында депутатлар Конституция Советына әгъзалар расладылар. Алар – Роман Гафаров, Эльмира Мостафина һәм Илгиз Гыйлаҗев. Шул өчлектән Илгиз Гыйлаҗевны Конституция Советы рәисе итеп тәкъдим иттеләр. Татарстан Югары суды рәисе булып эшләп отставкага киткән Илгиз әфәнде – бу вазыйфага бик лаеклы шәхес, тәҗрибәле юрист, шуңа күрә депутатлар аның кандидатурасын бердәм хупладылар.

Сессия утырышлары турында язган саен, безгә үз законнарыбызны федераль законнар белән тәңгәлләштерү турында сүз кузгатырга туры килә. Бу, күрәсең, сәясәт белән кызыксынучыларның кайберләренә бик ошап бетми. «Федераль законнар белән яшәгәч, безгә үз законнарыбыз нәрсәгә? Парламентның да кирәге шулкадәр генә», – дип әйтүчеләр дә бар. Бәхәсләшеп вакыт уздырасы килми, бары тик: «Без федераль закон кысасында, Татарстанның үзенчәлекләрен исәпкә алып, үз законнарыбызны язабыз. Хәтта үзебез язган кайбер закон проектларын Россия Думасына да тәкъдим итәбез һәм алар, гадәттә, гамәлгә керә», – дип куйыйк та вәссәлам.

Мәсәлән, кичә узган утырышта да парламентыбыз Россия Салым кодексына үзгәрешләр кертү буенча закон проекты кабул итте һәм аны озакка сузмыйча Думага юллаячаклар. Әлеге үзгәреш салым турында закон бозылган очракта гаепләне җинаять җәзасына тартуга кагыла. Безнең закон чыгару инициативасын Думага үзебездән сайланган депутат Айрат Фәррахов җитәкләячәк.

Пилотсыз очкыч җибәрүчегә 500 мең сум штраф янаячак. Бу хакта Дәүсовет утырышында республика прокуроры Илдус Нәфыйков чыгыш ясады. Депутатлар аның тәкъдимен бердәм хупладылар. Прокурор әйтүенчә, мондый закон проекты әлегә Россиядә бердәнбер.

Көн тәртибендәге тагын берничә мәсьәләгә тукталыйк әле. «2023 елга һәм 2024–2025 елларга Татарстан бюджеты турында»гы Законга үзгәреш кертү турында бәхәс булмый калмас, дип өметләнгән идек – барып чыкмады. Чөнки «заманына күрә капкачы» дигәндәй, без бөтен авырлыкларга каршы торырга өйрәнеп беттек бугай инде. Чыгыш ясаучылар әйтүенчә, төрле чикләүләргә карамастан, узган ярты еллыкта Татарстан икътисады тотрыклы эшләгән. Дөрес, чыгымнар күп булу сәбәпле, бюджет кытлыгы арткан үзе, әмма, финанс министры Радик Гайзатуллин фикеренчә, бюджет үтәлешендә проблема булмаячак. Финанс өлкәсендә «бер пот тоз ашаган» Радик Гайзатуллиннан моңа хәтле нигезсез, буш сүз ишетмәдек. Шуңа күрә республика бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәр хисабына алга таба да тулыланачагына ышанабыз. Саннарга килсәк, быел республика бюджетының керем өлеше 26526,2 млн сумга артып, 370459,9 миллион тәшкил итәр дип фаразлана. Ә бюджет кытлыгын капларга, министр әйтүенчә, чыганаклар бар.

Таксиларда пассажирлар йөртүгә кагылышлы закон проекты бераз бәхәс кузгатты үзе, тик кайбер «аңлату эшләре» алып барганнан соң беренче укылышта һәм тулаем кабул ителде. Чөнки депутат Александр Тыгин әйтмешли, «әлеге проект нигезендә такси пассажирларының мәнфәгатьләрен яклау һәм иминлеген тәэмин итү ята». Транспорт һәм юл хуҗалыгы министры Фәрит Хәнифов чыгышыннан аңлавыбызча, такси йөртүчеләр даирәсе киңәя, хәзер бу эштә юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр генә түгел, үзмәшгульләр дә катнаша ала. Әмма шул ук вакытта бу эшчәнлек таксига заказ бирү хезмәте аркылы алып барылачак һәм пассажирның иминлеге, аңа уңайлы шартлар тудыру өчен әлеге хезмәт җавап бирәчәк. Закон проекты такси машинасының төсенә дә аерым таләп куя, Татарстанда алар йә ак, йә сары төстә булырга тиеш. Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе Александр Тыгин әйтүенчә, яңа система сентябрьдә эшли башларга тиеш. Һәм яңа таләпләргә тәмам иямәшер өчен бишьеллык күчеш чоры да каралган.

Тагын бер закон проекты Украинада барган махсус хәрби операциягә бәйле. Бездә ятимнәрне торак белән тәэмин итүгә кагылышлы закон бар иде инде. Хәзер торакка мохтаҗлар исемлегенә хәрби операциядә катнашканнарның балалары да өстәләчәк.

Хәзергә шулар, дияр идек тә, парламентта профессиональ нигездә эшләүче депутатларның ишәю турында да әйтеп кую кирәктер дип уйладык. Татарстан Фәннәр академиясенең элекке президенты Мәгъзүм Сәлахов парламентның Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетында эшли башлаячак.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

tatarstan.ru

АЧЫК ПАРЛАМЕНТ

Республиканың икътисадый үсеше, балаларны ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү һәм хатыннан бер киңәш. Татарстан Парламенты җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советы депутатларының беренче яртыеллыкта башкарган эшенә йомгак ясады.

– Бу елның беренче яртысы шактый киеренке узды. Татарстан Дәүләт Советы тарафыннан 6 утырыш үткәрелде. Аларда 140тан артык мәсьәлә карап тикшерелде, 200дән күбрәк карар кабул ителде. Дәүләт Советы һәм Татарстан Рәисе тарафыннан 56 закон имзаланды, – диде Фәрит Мөхәммәтшин журналистлар белән очрашуда.

Парламент җитәкчесе әйтүенчә, депутатлар кулыннан узган канун проектлары тормышның төрле өлкәләренә кагыла. Бу – шул исәптән икътисад да, социаль яклау да, бизнеска ярдәм чаралары да. Фәрит Мөхәммәтшин соңгысына аерым тукталды.

– Бизнеска һәрвакыт булышып торырга кирәк. Илгә каршы кертелгән санкцияләр республика предприятиеләрен дә шактый катлаулы хәлдә калдырды. Нефть чыгару күләме кимеде. Безне республикада үз вакытында нефть эшкәртү сәнәгатен аякка бастыру коткарды. Без хәзер коры «кара алтын» гына түгел, ә нефть эшкәртү продукциясен дә сатабыз. Болар барысы да Татарстан икътисадын саклап калырга һәм күпмедер дәрәҗәдә үстерергә ярдәм итте, – диде Парламент җитәкчесе.

Бу яртыеллыкта каралган тагын бер мөһим мәсьәлә – чүп реформасы турында сөйләгәндә, Фәрит Мөхәммәтшин депутатлар корпусын бераз тәнкыйтьләп тә алды.

– Бәлки, без үзебез тиешенчә эшләп бетермибездер, – диде ул. – Халыкның каты көнкүреш калдыкларына бәйле зары бик күп: чүплекләр тулган, күл буена чүп-чар бушатып киткәннәр. Бу мәсьәләдә җирле үзидарә органнары һәм чүпне җыю һәм утильләштерү белән шөгыльләнүче оешма арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салырга кирәк. Көзге сессиядә моңа кабат әйләнеп кайтачакбыз. Югыйсә бәяләрне күтәрәләр, ә эшләре шулкадәр генә. Чүп җыючы операторлар үз эшенә җаваплырак карарга тиеш.

Депутатларны ватанпәрвәрлек, үсеп килүче буынга тәрбия бирү мәсьәләсе дә борчый.

– Гаилә тәрбиясе беренче урында, – ди Татарстан Дәүләт Советы Рәисе. – Баланы мәктәпкә биргәнче, сабый тәрбия нигезләрен нәкъ менә гаиләдән ала, әти-әнисеннән, туганнарыннан күреп өйрәнә. Шуңа күрә дә әлеге мәсьәләне Питрәч районында узган күчмә утырышта күтәрдек. Безнең тәкъдимнәрне хупладылар һәм моңа бәйле канун кабул итү озак көттермәс дип уйлыйм. Тәрбия бирү гаилә, балалар бакчасы, мәктәп белән генә чикләнеп калмыйча, бу эштә бөтен тармак министрлыклары, яшьләр оешмалары да катнашырга тиеш. Бүген ватанпәрвәрлек мәсьәләсе дә бик мөһим. Чөнки безгә каршы чыккан илләр күпмилләтле республикаларга игътибарын арттырып, ниндидер авырлык китерергә тырышалар. Менә шуны аңлатып бирә белү мөһим.

Җәйге ялга кадәр үткәрелгән соңгы утырышта беренче тапкыр Конституция советы вәкилләре сайланды. Журналистлар Фәрит Мөхәммәтшиннан яңа органга карата фикерен сорады.

– Федераль үзәк төбәкләрдәге Конституция судларын бетерү турында карар кабул итте. Без моңа каршы идек. Шәхсән үзем бу хакта Мәскәүдә чыгыш ясадым. Чөнки шул рәвешле гади халыкның тормышын катлауландыралар. Бөтен кеше дә зар-интизары белән Мәскәүгә кадәр барып җитә алмый бит. Тик бернишләтеп тә булмый, канун кабул ителде. Шуңа күрә «Татарстанда моңа охшаш орган кирәкме?» дигән сорау туды. Бу мәсьәләдә безне Рөстәм Миңнеханов та хуплады. Татарстан Конституция советына башкарма хакимият органнары да, халык та мөрәҗәгать итә алачак. Әйе, суд вәкаләтләре юк. Әмма мөрәҗәгатьләргә җавап табып, язмача киңәш-тәкъдимнәр бирәчәкләр. Ул тиешенчә эшләп китсен, нәтиҗәле булсын өчен вакыт кына кирәк. Күрше республикаларда, мәсәлән, Башкортстанда мондый орган бар инде, – диде Парламент җитәкчесе.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе республиканың каләм әһелләрен дә мактады. Аның әйтүенчә, Татарстан Парламенты ил күләмендә мәгълүмати яктан иң ачыгы дип табылган. «Монда сезнең дә өлеш бар», – диде ул журналистларга.

Форсаттан файдаланып, Фәрит Мөхәммәтшиннан: «Киләсе елга билгеләнгән сайлауда үз кандидатурагызны тәкъдим итәчәксезме?» – дип тә сорадылар. Парламент җитәкчесе дөресен әйтергәме-юкмы дигән кебек бераз елмаеп торды да:

– Яшь бара. Дәүләт Советы Рәисе буларак та, Россия Закон чыгаручылар Советында да эш шактый. Мәскәүгә дә еш барырга туры килә. Республикада да эш җитәрлек. Илнең иң зур сәяси партиясе булып саналган «Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре булу да, башка эшләр дә күп вакыт һәм көч таләп итә. Хатын да: «Җитте инде сиңа», – дип әйтте, – диде, уенын-чынын бергә кушып. – Шуңа күрә киләсе елда сайлауда катнашмамдыр, мөгаен. Карарбыз. Илдә-көндә хәлләр ничек булыр. Мактанып әйтүем түгел: Парламент Рәисе буларак 25 еллык тәҗрибәм бар. Хөкүмәттәге барлык эшчәнлегем – күз алдыгызда. Тәҗрибә белән бергә эшнең күләме дә артты. Шуңа күрә, әгәр бу вазыйфага дәгъва итмәсәм, Парламент Рәисе булырлык алмаш әзерлисе булыр.

Ныклы карарга килгәнче Рөстәм Миңнеханов һәм Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев белән дә киңәшләшергә җыенуын әйтте ул. Уйларга бер ел вакыт бар әле. Әлегә исә депутатлар ялга таралышты.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Халык кәефе

Уракка төштегезме?

Язның иртә килүе һәм корылык авыл хезмәтчәннәрен тагын бер кат сынады. Күп кенә районнарда урып-җыюга керештеләр. Уңышка өмет бармы? Авыл халкы нәрсәгә өметләнә. Без аларның хәлен белештек.

Марсель ШӘЙДУЛЛИН,
Азнакай районы башлыгы:

– Район тулысынча уракка әзер. Һава торышының җайланып китүен көтәбез. Бу көннәрдә яңгыр да явып тора бит әле. Быел безнең якларда яңгыр булмады. Игеннәр өлгерде инде, әмма өмет зурдан түгел. Гектарына 15 центнер ашлык ала алсак, бик тә яхшы булыр иде. Арпа бик кыска гына үсте. Атна ахырына басуга чыгачакбыз. Быел игеннәрне егып аласы була инде. Кыска булып үстеләр. Күңелне төшермибез. Узган елгы запаслар да бар бит әле. Быел бездә печән дә бик булмады. Халыкка һәм хуҗалыкларга өләшер өчен күрше төбәкләр, башка районнардан бер төргәген 2–3 мең сумга сатып алып таратабыз. Мал санын киметеп булмый бит инде. Районда 30 меңгә якын мал бар.

Илфар ХАЛИКОВ,
Минзәлә районы авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы:

– Корылык булса да, күңелне төшермибез. Өметсез шайтан гына, диләр бит. Былтыргы кебек икмәк булмас инде ул. Без узган ел гектарыннан 46 центнер ашлык урган идек. Бүген-иртәгә эшкә керешәчәкбез. Яңгырлар комачау итмәсә, инде уракка тотынасы идек. Быел яз иртә килү һәм корылык аркасында басуларга алданрак чыгабыз. Узган ел уракка 2 августта төшкән булганбыз. Бездә әле кичә нык кына яңгыр яуды. Бездәге хәлләр 2010 елдан да начаррак.

Мин күзәтүләр алып барам. 2010 елның 1 гыйнварыннан 13 июльгә кадәр 126 мм явым-төшем булса, быел 90 мм гына. Узган ел исә 228 мм иде. Шуннан чыгып, уйлап карагыз инде. Өмет әллә ни юк. Булганын вакытында җыеп алырга иде.

Марат МИНГАЛИЕВ,
Балык Бистәсе районы авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы:

– Басулар әзер инде. Без уракка чәршәмбе көнне үк тотынаса идек. Яңгыр комачаулады. Әгәр көн аязып китсә, эшкә тотыначакбыз. Бездә дә яңгыр әллә ни булмады. Апрель башыннан бирле җиргә 40 мм яңгыр яуган. Әмма 2010 елга караганда хәлләр яхшырак. Ул елгы корылык безне эшләргә өйрәтте. Без хәзер вакытында печән әзерлибез, күп итеп сенаж хәстәрләп куйдык. Печәнне күршеләргә дә сата башладык. Быел ашлык чүплерәк булыр дип торабыз. Гектарыннан 20 центнер уңыш алырга исәп бар. Быел аеруча бодай яхшы күренә.

Николай ТУГАШЕВ,
Зәй районы «Восток» агрофирмасы агрономы:

– Без урып-җыюга 11 июльдә тотындык. Ул көнне 67 гектарда арпа суктырып алдык. Аның уңышы гектарыннан 23,9 центнер чыкты. Быелгы корылык, әле аның өстенә 7–9 майда урыны-урыны белән 11 градуска кадәр салкын булуны исәпкә алсак, бу начар күрсәткеч түгел. Шушы өч көн эчендә арпа, борчак басулары өшегән иде. Коткарып кала алмадык, дип, өметне өзгән идек. Вакытында тиешле препаратлар кулланып, без басудагы уҗымнарны саклап кала алдык. Алар киредән яңарды. Кайсыдыр басуларда арпа тагын күбрәк чыга әле. Шушы көннәрдәге яңгырлар башка культурага яхшы булды. Анысына да сөендек. Без быелгы уңыш начар булыр дигән уйда түгел. Алдан булса да әйтим инде, көзге бодай белән арпа уңышы яхшы булыр, дип торабыз. Аны гектарыннан 38–40 центнер алырга ниятлибез.

Татарстан районнарында – урып-җыю

Район	Суктырылган ашлык, тоннада	Уңдырышлылык ц/га
Аксубай	328	25,4
Актаныш	102	12
Алексеевск	943	30
Әлки	2870	28,8
Апас	261	26,1
Буа	511	35
Зәй	1815	35,2
Түбән Кама	200	40
Яңа Чишмә	280	28
Нурлат	1111	45,9
Тукай	86	34,5
Чистай	125	25
Татарстан	**8632**	**30,8**

Әйтеп кенә бактым

Акча

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Никита Сергеевич Хрущев 1980 елга коммунизм вәгъдә иткәч, укытучыларыбыз безгә әлеге җәмгыятьнең нинди булачагын аңлата башлады. Анда байлар да, ярлылар да булмаячак, бөтен кеше бертигез яшәячәк икән. Безнең өчен иң сәере – балаларны иң сөендергәне – акчаның юкка чыгуы иде. Акчасыз ничек яшәргә була икән соң ул?

Әниләр Сабан туена 10 тиен акча бирә иде дә, мәйданның иң кызган чагында шуңа бераз печенье алып ашый идек. Акча беткәч, нәрсә ашарбыз, биш тиенгә билет алып, кино да карап булмас. Коммунизмда «һәркемнән сәләтенчә, һәркемгә хаҗәтенчә» дигән закон булачак икән. Баштарак моның ни-нәрсә икәнен аңлап бетермәдек, хәтта «хаҗәт» дигәне нәрсә икән, дип аптырадык. Өлкәннәр аны «кирәк нәрсә» дип аңлаткач, ничек шатлануыбызны үзебез генә беләбез. Кибеттән, бер тиен дә түләмичә, үзеңә ни кирәк – шуны алып кайтып булачак икән бит! Олы абзый-апалар: «Әкият бу», – дип баш селкеде, ә без ышандык. Коммунизмга барып керергә әле егерме еллап вакыт бар, шул вакыт эчендә ниләр булмас, дип уйладык. Әйе, бик озак вакыт кебек тоелды безгә бу егерме ел. Әле исәпләп тә карадым: коммунизм җиткәндә миңа 31 яшь тулачак һәм: «Әле бик карт булмыйм икән!» – дип шатланып йөргәннәр дә истә.

Башыма төрле уйлар керә торды. Бигрәк тә коммунизмның төп законындагы «һәркемнән сәләтенчә, һәркемгә хаҗәтенчә» дигән сүзләрне төшләремдә саташып әйтә башладым. Чамалы Мәхмүте кибетеннән бер тиен түләмичә, ни кирәк – шуны алып кайт әле! Кибетче алган әйберне күпсенә башласа: «һәркемгә хаҗәтенчә», – дип кенә кыстырып куясың. Каршы килеп кенә карасын Чамалы Мәхмүте коммунизмның төп законына! Силсәвиткә чакыртып иманын өшкерәчәкләр…

Менә 20 ел вакыт узып та китте. 1980 елда коммунизмны күрәсе урынга, телевизордан Мәскәүдә узган Олимпия уеннарын карадык без. Коммунизм кебек үк булмаса да, бөтен дөньяны шаулаткан спорт бәйрәме иде ул. Олимпия уеннары ябылу тантанасында стадион өстенә күтәрелгән «Олимпийский мишка»ны зәңгәр күктә эреп югалганчы бөтен халык елый-елый озатты…

Ә күңел дигәнең һаман да ниндидер могҗиза көтеп яшәде. Акчаның юкка чыкмасы аяз көн кебек ачык иде. Дөрес, Горбачев, Ельцин хакимлек иткән заманнарда хезмәт иясе халкының бер өлеше акчасыз яшәп алды. Әллә ничә айлар буе хезмәт хакы күрмәгәннәр әти-әни пенсиясенә көн күрә башлады. Телгә «бартер» дигән ят сүз килеп керде, акча урынына әйбер белән алыш-биреш китте. Әмма акча дигәннәре озын гомерле булса да булыр икән! 1990 нчы елларда, җәмгыятьнең кыйбласы 180 градуска үзгәргәч, акча, гомумән, дөнья тоткасына әйләнде. Бөтен нәрсә акчага сатыла торган заман килде.

«Һәркемнән сәләтенчә, һәркемгә хаҗәтенчә» дигән сүзләр әйтүчегә бүген диванага караган кебек карарлар, билләһи! Их, Никита Сергеевич, карап торышка әйбәт кенә, акыллы гына кеше төсле идең, тормышка ашмастай хыялый уйлар башкаеңа ничекләр генә керде икән соң? Бөтен кеше бертигез була алмый бит инде ул! Кулдагы бармаклар да бертигез түгел.

Акча кешелек тарихында беренче мәртәбә безнең эрага чаклы VII гасырларда барлыкка килгән. Шул гомер яшәгән акчаны бер кеше генә юкка чыгара аламыни, Никита Сергеевич?! Әлбәттә, ул заманнарда ерак бабаларыбыз акча урынына төрле ташлар, кабырчыклар кулланганнар, ди. Ә хәзер кеше гомере акча урынына йөри. Акча түләп кеше үтерәләр. Әнә Украинага акча артыннан килгән чит ил солдатлары 11 меңнән артып киткән, ди. Алар Украинаның мөстәкыйльлеге хакына гомерләрен бирергә әзер торучылар түгел. Алар – акчага ялланган кеше үтерүчеләр, аларга украин ни, урыс ни, татар ни, чуаш ни – бары тик түләсеннәр генә. Әйтүләренчә, безнекеләр аларның яртысына якынын юкка чыгарган инде, шуңа күрә Украинага атлыгып торучылар да кимегән, ди. Әмма акча дигәннәре һаман да котлы тарата әле.

Бүген дөнья урталай бүленде: бер якта – фикердәшләр белән без, икенче якта – үзенең куштаннары белән Америка. Уртада шайтан вәсвәсәсе дәрәҗәсенә җиткән акча, җир, байлык һәм… «Кем кемне?» дигән сорау. Никита Сергеевичны бүгенгә кайтарсаң, ни дияр инде икән? Ул Американы куып җиту һәм узып китү турында хыялланган иде. Әлеге хыялның һаман да тормышка ашмаганын күрер дә Джо Байденга ачу белән: «Мы вам покажем Кузькину мать», – дип әйтеп куяр сыман. Бу гыйбарә татарча «күрмәгәнегезне күрсәтү» дигән мәгънәдә инде. Бу сүзләрне әле Хрущев 1959 елны ук Америка делегациясе белән очрашуда әйткән, диләр. Калганын үзегез уйлап бетерегез!

ҮЗЕҢНЕКЕ – ҮЗӘКТӘ

Соңгы көннәрдә ясалган төрек инициативалары Россиянең ура-патриотлары арасында зур гасабилану тудырды. Әрдоганны хыянәттә, сүздә тормауда, килешүләрне үтәмәүдә һәм шуларга бәйле рәвештә Кремльне төрек кубызына биюдә гаепләүләр баштан ашып китте.

Әнкараның, Россия белән килешүләрне бозып, «Азов»* командирларын Украинага кайтаруы, Украинаның НАТО составына алынуын яклавы, Киевка Firtina T-155 үзйөрешле артиллерия җайланмалары бирелү, Кремль теләгәнә каршы килеп, «ашлык килешүе»н озайтырга җыенуы – барысы бергә Владимир Путин аркасына кадалган пычак булып кабул ителә һәм Россия лидерының имиджын начарайтучы гамәл дип бәяләнәләр. Аңлашыла инде: ура-патриотлар җавап бирүне, Әрдоганнан рәхимсез үч алуны таләп итә. Соңгысы – «ашлык килешүе», гомумән, баштан ук Россия мәнфәгатьләренә каршы килә дип санала иде һәм «диван сәясәтчеләре» Кремльдән аны өзүне күп тапкыр таләп итте. Зур сәясәт әһелләре арасында да, хәтта Кремльнең үзендә дә Украина ашлыгын экспортлауга юл куелуны гел авыр кабул иттеләр. Күп вакыт тешне кысып түзәргә туры килде, чөнки Мәскәүдә бу килешүне Россия һәм Белоруссия продукциясен (иң беренче чиратта калийлы һәм азотлы ашламаларны) Европага һәм Африкага сату мөмкинлегенә бәйлиләр иде. Берничә тапкыр озайтылган «ашлык килешүе» ул мөмкинлекне бирмәде һәм Россия, ниһаять, килешүдән чыгачагын өзеп әйтте. Югарыда сөйләнгәннәр барысы да Әрдоганның астыртынлыгы һәм хыянәте буларак кабул ителә.

Хәзерге дөньяда зур сәясәтнең ничек эшләнүен белмәү нәтиҗәсе болар. Әйдәгез, Төркиядә күптән түгел генә булып узган президент сайлавын искә төшерик. Ике турда үтү сәбәпле, ул дөньякүләм сәясәттә кемнәрнең кем икәнлеген ачыкларга зур мөмкинлек бирде. Европада һәм АКШта Әрдоганның яңа президентлык срогына каршы ачыктан-ачык сугыш игълан ителде. Матбугат һәм телевидение төрек лидеры өстенә шулкадәр күп пычрак өйде, хәтта аны чистартып бетереп булмас кебек иде. Сайлауның хәлиткеч этабы якынлашканда, Әрдоган АКШ Президенты Байденның аны бәреп төшерергә әмер бирүе турында да белдерде. 14 май көнне бу хакта көрдләрнең Rudaw агентлыгы хәбәр итте. Гадәти кеше акылы белән фикер йөртсәк, сайлауда җиңгәннән соң, төрек лидеры американнарга гомерлек дошман булып калырга һәм беркайчан да Байден белән бер өстәл янына утырмаска тиеш иде. Әрдоган әле 2018 елда ук АКШ сәясәтчеләре адресына: «Бер яктан сез стратегик союз турында сөйлисез, икенче яктан партнерыгызның аркасына пычак кадыйсыз. Без моны кабул итә алмыйбыз», – дигән иде.

Соңгы көннәр белдерүләрен игътибар белән укыйк әле. Вильнюс саммиты кысасында Төркия белән Көнбатыш арасында чып-чын сәүдә барды. Төрекләр мөмкинлектән файдаланып калу өчен барысын да эшләде: Швециянең НАТОга керүен Төркиянең Евросоюзга кабул ителүенә бәйләделәр. Бу уңайдан Вашингтонның белдерүен карыйк: «АКШ һәрвакытта да Төркиянең Евросоюз әгъзасы булуга омтылышын яклады һәм яклавын дәвам итә». НАТО генераль секретаре Йенс Столтенберг та шуны ук яклый икән, ул да үз сүзен өзеп әйтте. Шведларны әйтеп тормыйбыз, алар ике куллап төрекләр яклы. Американнар кичекмәстән F-16 очкычларын Әнкарага сатарга карар кабул иткәннәр, Гыйракта һәм Сүриядәге төрек хәрби операцияләрен дә яклыйлар дигән хәбәрләр дә таралды. Байден белән очрашкач, Әрдоган да үз «Твиттер»ында: «АКШ белән яңа этап башлыйбыз», – дигән сүзләр язды. Алдагы вазгыятьне белмәсәк, Төркия – Көнбатыш дуслыгына моңарчы Әнкара аяк терәп каршы торган, көнбатышлыларның исә һәрвакытта да төрекләргә мәхәббәте ташыган дип аңлар идек. Вазгыять менә шулай кискен үзгәрә ала: глобаль сәясәттә мәңгелек дошманнар да, мәңгелек дуслар да юк. Шәхси үпкәләр һәм амбицияләр ил мәнфәгатьләре алдында һәрвакыт артка чигә. Зуррак отыш хакына кечерәк нәрсәләрне корбан итү гадәти хәл санала.

Хәзер Әрдоганның Россиягә хыянәте мәсьәләсенә әйләнеп кайтыйк. Сайлаудан соң Төркия сәясәтендә (кем җиңүгә карамастан) җитди борылышлар булачагын бу юлларның авторы алдан әйткән иде. «Икенче тур нинди генә нәтиҗә белән төгәлләнмәсен, дөнья сәясәтенең шахмат тактасында төрек гамбиты башлануга китерергә мөмкин», – дип майда ук яздык. Вильнюс очрашуы алдыннан һәм саммит вакытында без шул гамбитның беренче йөрешләрен күрдек. Россия мәнфәгатьләре өчен зур зыян китерерлек берни дә булмады диярлек анда. Килешү буенча, сугыш беткәнче, Төркиядә яшәргә тиешле 4–5 кешенең Украинага кайтуы эмоциональ эффекттан башка берни дә бирми. Ни тактик, ни стратегик әһәмияте дә юк аның. Моннан соңгы килешүләрдә төрекләргә йөз процентка ышанып бетәргә ярамый дигән нәтиҗә генә ясала ала. Владимир Путин сүзчесе Дмитрий Песков нәкъ шундый нәтиҗәне әйтте дә. Әйе, мәскәүдәгеләрнең кытыгына бик каты тигән бу гамәл, үпкә зур, төрекләрнең Кремльне санга сукмавы буларак кабул ителә. Әмма… төрекләргә үч итеп, уртак проектларны утта ягарга һич кенә дә ярамый. Бер нәрсәне яхшы аңларга кирәк: Әнкараның Мәскәү белән хезмәттәшлеге мәхәббәттән түгел, файда күзлегеннән генә чыгып башкарыла. Төркия беркайчан да Кырымны Россиянеке дип санамады, Донбасстан Россия гаскәрләре чыгарылырга тиешлеген дә даими әйтеп тора. «Азов» сугышчылары да төрек пропагандасы күзлегеннән караганда нацистлар түгел. Алар Төркиягә алмашу нәтиҗәсендә китте (ягъни Россия аларны бушка бирмәде) һәм Әнкара ни өчен килешүнең бер өлешен үтәмәвен Мәскәүгә үзе аңлатыр. Дипломатия эше бу, хисләр белән хәл ителә торган мәсьәлә түгел. Кремль вазгыятькә мондый күзлек белән карый: «Перспективы реализации проекта газового хаба с Турцией никак не связаны с ситуацией вокруг передачи главарей «Азова». Аш – ашка, урыны – башка ягъни. Төркиядә газ саклагыч төзү төрекләр өчен – отышлы, Мәскәү өчен – кирәк. Бер нәрсәне истә тотыйк: Европага газ сатуны чикләү Россиянең 2023 ел бюджетына 2,6 триллион сумлык югалту бирә. Аз акча түгел. Көньяк аша газның бер өлешен сатып була икән, ул варианттан баш тартырга ярамый. Төрекләрнең Украинага корал сатуы бик ачуны китерергә мөмкин, әлбәттә, әмма Пескова сүз бирик: «У Турции есть абсолютное право развивать отношения с Украиной, но Россия надеется, что это не будет направлено против Москвы». Өметләнеп була, таләп итеп булмый. Ярым-йорты дәүләт белән түгел, төбәк державасы белән эш итәбез. Әле ул глобаль масштабта да үзен зур көч буларак игълан итә.

Ашлык килешүе – Россия өчен сызландыра торган мәсьәлә. Ә төрекләр өчен ул – матди отыш китерә торган проект. Әрдоган килешүне озынайтырга кирәк дип саный икән, Россиядән башка да озайтачак. Моның өчен җитәрлек куәте бар. Әйе, Россия, Одесса портындагы инфраструктураны җимереп, экспортка аяк чала ала, әмма Әнкара белән араны бозар алдыннан җиде кат үлчәргә кирәк булачак. Төрек дипломатиясе килешүдә Россиянең катнашуы Мәскәүнең йөзен саклау өчен генә кирәк дип саный. Кремльдә теләмиләр икән, рәхим итсеннәр: Әнкара инде, ашлык килешүе, Россия аннан формаль рәвештә чыкса да, озайтылачак, төрек хәрби диңгез көчләре «коридор»ның куркынычсызлыгын тәэмин итәчәк, дип белдерде. Килешүдән чыгу Кремль өчен имидж югалтуы бирә, башка берни дә түгел.

Зур сәясәтнең сыгылмалылыктан башка була алмавын Кремльнең Пригожин фетнәсенә мөнәсәбәте мисалында да күрә алабыз. 24 июнь көнне Владимир Путин Россия гражданнарына мөрәҗәгатендә: «Тот, кто организовал и готовил военный мятеж, кто поднял оружие на боевых товарищей – предали Россию. И ответят за это», – дип белдергән иде. Соңыннан чишелешнең компромисслы варианты табылды.

Зур сәясәттә бирелгән вәгъдәләрнең тиз онытылуы – гадәти күренеш. Сайлаудан соң Әрдоган тышкы сәясәттә яңа сәхифә ачмый булдыра алмый иде. Төркиянең икътисадый хәле, сайлау алдыннан халыкка биргән вәгъдәләр шуңа мәҗбүр итә. Зур вәгъдәләрнең үтәлүе хакына әһәмияте ягыннан кечерәк булган принципларны бозу хәзерге дөньяда хыянәт дип түгел, прагматиклык дип санала. Әрдоганның соңгы көннәр йөреше – шул прагматиклыкның бер чагылышы ул. Сәясәтнең шахмат тактасында шундый ат йөрешләреннән башка ерак китә алмыйсың.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

* Россиядә тыелган террорчылык оешмасы.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

ДОЛЛАР БИЮЕ

ВАЛЮТА БАЗАРЫНДАГЫ ТОТРЫКСЫЗЛЫК БӘЯЛӘРГӘ ТӘЭСИР ИТӘЧӘКМЕ?

Көнкүреш техникасы, кием-салым һәм машина. Доллар кискен үсү аркасында, барыннан да бигрәк, әнә шул төр товарларга бәяләр артачак, ди белгечләр. Хәер, алар да белеп бетерми бугай. Көн дә ашый торган суган да чит ил валютасы артыннан куа әнә. Бу атнада аның бер килосы 70 сумлык чиккә җиткән. Валюта базарындагы тотрыксызлык бәяләргә ничек тәэсир итте? Кесәдәге акчаны нишләтергә? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

Тәгәри китте рубль

Июнь башыннан бирле доллар курсы рубльгә карата 11,5 процентка (81,1 сумнан 90,4 сумга кадәр), ә евро курсы 14,8 процентка (86,5 сумнан 99,3 сумга кадәр) үсте. Берничә айдан бирле үз кыйммәтен югалтучы рубль май аенда бераз тотрыкланса, җәйгә кергәч кабат түбән тәгәри башлады. Ә июнь азагында «Вагнер» шәхси хәрби компаниясе тирәсендәге вакыйгалар тәмам тынычлыкны урлады булса кирәк. 6 июль көнне доллар – 94, ә евро 102 сумлык чикне узды. Әлеге язма газетага әзерләнгәндә чит ил валюталары 90 сум 63 тиен һәм 99 сум 89 тиен тора иде. Акча базарында хәлләр әнә шундый. Доллар курсы бер атнадан бирле 90 сумлык чиктән төшми. Чагыштыру өчен: узган елның июлендә ул иң күбе 63 сум 14 тиен торган. Рубль узган елның мартындагы тискәре рекордын яңартты.

– Доллар чама белән 10 процентка кыйммәтләнгән икән, димәк, бәяләр дә ким дигәндә шулкадәр артачак, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин. – Моңа җитештерүчеләр, арадашчылар һәм кибет хуҗалары өстәгән кыйммәтне дә кушсаң, валюта базарындагы соңгы вакыйгалар аркасында бәяләр 15–20 процентка кадәр артачагына гаҗәпләнәсе юк.

Татар күрми ышанмый, ди. Шуңа күрә без дә бүгенге бәяләргә күз салдык.

Телевизор тик тора

– Долларга бәйле рәвештә бәяләр артырга өлгермәде әле. Иске бәя белән кайткан товарны сатабыз, – ди башкаладагы көнкүреш техникасы сатучы кибетләрнең берсендә өлкән сатучы булып эшләүче Искәндәр Насыйров. – Доллар күтәрелү эзсез генә узмаячак, әлбәттә. Тик әлегә бу хакта бер сүз дә әйтүче юк. Көтәбез. Дөресен генә әйткәндә, соңгы бер ел – ел ярымда бәяләрнең артудан туктаганы да юк. Хәтерләсәгез, былтыр доллар кинәт югары сикергәч, халык дәррәү кубып көнкүреш техникасы кибетләреннән телевизор-суыткыч сатып ала башлады. Киштәләр бушап калды хәтта. Быел андый хәл юк. Сатып алучылар күп түгел. Кирәкле көнкүреш техникасын былтыр ук запас белән алып бетергәннәр, ахры *(көлә)*. Доллар кыйммәтләнү иң беренче чиратта параллель импорт буенча кайтучы товарларга тәэсир итәчәк. «Параллель» техниканы күбрәк Үзбәкстанда җыялар. Сыйфаты элеккеге кер юу машиналары, суыткычлардан бераз калыша. Әлегә кибеттә Европа товарлары җитәрлек. Шуңа күрә якын арада көнкүреш техникасы сатып алырга теләүчеләргә тизрәк уйларга киңәш итәбез.

Әй, машина, машина...

– Бәяләр үсү күптән гадәти хәлгә әйләнде бит инде, – ди башкалада «Hyundai» автомобильләре сатылучы салонда эшләүче Артур Сафин. – Машиналар илгә нигездә параллель импорт буенча Казахстаннан кайтарыла. Баштарак мондый автомобильләргә салонда 400–500 мең сумга кадәр ташлама ясый идек. Хәзер акцияләр юк диярлек.

Чит илнеке генә түгел, үзебезнең «тимер ат»ларны сатып алырга да калын акча янчыгы кирәкмәгәе. Бу көннәрдә Екатеринбургта узган «Иннопром – 2023» халыкара сәнәгать күргәзмәсендә «АвтоВАЗ» генераль директоры Максим Соколов тел яшереп тормады.

– Долларның рубльгә карата үсүе «Lada» автомобильләренең тәкъдим ителгән соңгы бәясенә тәэсир итәчәк, – диде ул. – Соңгы ике айда гына да читтән кайтучы машина комплектлары 15–20 процентка кыйммәтләнде. Без бәяләр артмасын өчен хәлдән килгәнне эшләячәкбез.

Сүз уңаеннан, бу җәйдә «АвтоВАЗ» Санкт-Петербургта яңа «Lada X-Cross 5» автомобильләре җитештерә башлады. Табадан яңа төшкән «тимер ат» якынча 2,5 миллион сум торачак, ди.

Пәлтәсез, әмма тораклы

– Милек базарында әллә ни үзгәреш юк, – ди риэлтор Наилә Садриева. – Гомумән, бу вакытта күчемсез милек базарында тынлык күзәтелә. Җәй, гадәттә, фатир сату-алу вакыты түгел. Арзанрак булгач, халык күбрәк икенчел торак базары белән кызыксына. Көзгә таба фатирны арендалау 15–20 процентка кадәр кыйммәтләнергә мөмкин. Сәбәпләре билгеле инде: шәһәргә студентлар килә.

Кием-салым сатучылар да көзне куркып көтә.

– Билгеле хәлләр аркасында, читтән сыйфатлы кием-салым алып кайту шактый читенләште, – ди Казанның «Бигзур» сәүдә үзәгендә эшләүче эшкуар Лениза ханым. – Безнең халык сыйфатлы тукымадан тегелгән, яхшы фурнитуралы күлмәк, пәлтәгә ияләшеп беткән иде инде. Хәзер сатып алучыларның зәвыгына туры килерлек кием-салым табу бик авыр. Яз көне Кытай, Төркия фабрикалары белән эшли башладык. Доллар кискен кыйммәтләнгәнче, көзге кием-салымга заказ биреп калырга өлгердем. Киемнәр арзан түгел, ирләр чалбары 5–6 мең сумнан башлана. Кышкы киемнәрне карарга да куркам. Доллар үскән дип, базардан ат бәясенә миннән кем куртка алсын?

Үзе түгел, бәясе елата

Доллар артыннан чит ил кояшы да кыйммәтләнгән.

– Моннан ике ай элек кенә АКШ валютасы 75 сум тирәсе тора иде, бүген ул 90 сумнан да кыйммәтрәк. Юллама бәяләре дә камыр кебек күперде, әлбәттә, – ди Чаллыдагы юлламалар сату агентлыгы хезмәткәре Айгөл Вафина. – Быелның май ае белән чагыштырганда, шул ук юлламаларны ким дигәндә 100 мең сумга кыйммәтрәккә сатабыз. Бүген Төркиядә август азагында дүрт кешегә бер атналык юллама бәясе 200 мең сумнан башлана. Арзан бит дисезме? Очып киткәндә юлда – бер көн, кире кайтканда – ярты көн югала чөнки. Җәйгә очу вакыты уңайлы булган юлламалар калмады инде. Доллар үсүдән туктаса, юллама бәяләре көзгә бераз төшәр, бәлки.

Чит ил кояшы еракта булса, суган үзебездә үсә дә бит, аннан ни файда? Ул да кыйммәтләнгән. Бу атнада социаль челтәрләрдә халык яшелчә, җиләк-җимеш базарында төшерелгән фотоларга бик гаҗәпләнде. «Җылы яктан кайткан абрикос, шәфталуның килограммы 100 сум торса, үзебездә үстерелә торган суган 70 сум», – дип аптырашты алар. «ВТ» хәбәрчесе яшелчә бәясен «Татарстанстат» сайтыннан белеште. 3 июльгә алынган мәгълүматларга караганда, республикада суганның бер килосы 63 сум тора. Белгечләр яшелчә бәясе артуын аңлатырга да тырышкан. Әйтүләренә караганда, әлегә үзебездә суганның яңа уңышы өлгермәгән, ә булганы исә беткән. Киштәгә исә ул Үзәк һәм Урта Азиядән кайта. Тик быел кояшлы илләрдә кыш артык салкын булу сәбәпле, Үзбәкстан, Таҗикстан һәм Казахстан яшелчәне читкә озатуга өлешчә чик куйган, ди.

«КЫЙММӘТЛЕ ТОВАР АЛЫРГА АШЫКМАГЫЗ»

Акчага бәйле үзгәрешләр турында Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис ХӨСӘЕНОВ белән сөйләштек.

:: Фәнис Сәярович, долларның үсүе, рубльнең түбән тәгәрәве якын киләчәктә бәяләргә ничек тәэсир итәчәк?

– Иң беренче чиратта шуңа ачыклык кертергә кирәк: доллар курсы тирбәлү якын арада ук туктаячакмы әллә бу озаграк вакыт дәвам итәчәкме? Без моны кыска вакытка исәпләнгән тотрыксызлык дип кабул итәбез. Чыннан да, әгәр бу бер ай – ай ярымга исәпләнгән сикереш икән, чит илдән кайтарылучы товарлар әллә ни кыйммәтләнмәячәк. Доллар курсы уйнау өч ай һәм аннан да күбрәк вакыт дәвам итсә, аңлашыла ки, алга таба кибетләргә товарны кыйммәтрәк бәядән кайтарырга туры киләчәк. Гомумән, валюта базарында вазгыять хәзерге кебек кискен үзгәргән шартларда, без халыкка ашыгыч адымнар ясамаска киңәш итәбез. Аңлатып китик: доллар бүген үссә, иртәгә нәкъ шулай кискен кимергә дә ихтимал. Без моны былтыр күрдек бит инде. АКШ валютасы 120 сумга кадәр күтәрелде дә кире 60 сумга төшеп утырды. Ә күпләр, мәсьәләнең төбенә төшәргә теләмичә, кибетләргә суыткыч, машина кебек кыйммәтле чит ил товарлары сатып алырга йөгерде. Соңыннан кыйммәтле бәядән сатып алган ике телевизор, өч кер юу машинасы белән утырып калдылар. Артык техниканы очсызракка юнәтүчеләр дә булгандыр әле. Халык көнкүреш техникасын запас белән сатып алды. Шуңа күрә бу җәйдә кибетләрдә ыгы-зыгы булмаячак.

:: Алда безне ни көтә?

– Әйткәнемчә, бу кыска вакытка исәпләнгән тотрыксызлык булырга тиеш. Бүген АКШ валютасы 90 сум тирәсендә тирбәлә. Уртача еллык курс исә 80–85 сумнан артмаячак дип фаразлыйбыз. Ел ахырында АКШ валютасы 80 сум тирәсе торырга мөмкин. Шуңа күрә тагын бер тапкыр әйтәм: бүген кыйммәтле товар сатып алырга ашыкмагыз. Сатучылар шуны гына көтә: халык билгесезлеккә чумган арада үзләренә кирәкле товарны яки кыйммәтлесен сатып калырга тырышалар.

:: Хәзерге шартларда доллар сатып алу яки аны сату отышлымы?

– Әгәр бер ел һәм аннан да күбрәк вакыт акча җыярга ниятлисез икән, чит ил валютасы сатып алырга мөмкин. Тик шунысы бар: аны тере акча итеп алырга кирәк. Ягъни әгәр валютаны счет ачсагыз, банктан әлеге сумманы алырга теләгән очракта сезгә исәп-хисапны ул вакытта гамәлдә булачак курс белән ясаячаклар. Ә доллар үскән дип кенә, кесәдәге юклы-барлы акчаны чит ил валютасына алмаштырудан файда юк.

Рафит Муллаянов фотолары

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

СҮНМӘСЕН ЙОЛДЫЗ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Татарстаннан бер төркем делегация белән Йолдыз авылына килеп төшкәндә, бирегә хәтта күләгәдә дә 40 градус эссе иде. Шушындый челләдә җиләк, үлән, чәчәк җыеп, печән әзерләү ише җәйге мәшәкатьләр белән маташ та, су кер дә бит... Йолдызда яшәүчеләрнең хәсрәте башка шул әлегә. Җиләк, чәчәк исенә, яшеллеккә күмелеп утырасы авыл быелгы җәендә сары көзен кичерә.

Тынычлыкны урлаган утлы фаҗига турында йортсыз бушап калган урамнар, агач кәүсәләренә сеңгән кара көл, әледән-әле борынга бәрелеп торган янгын исе, аякка ияреп йөргән кара корым гына искәртеп тора. Һәм, әлбәттә, халыкның борчулы күзләре. Хәер, төзелеш материаллары өелгән ишегаллары, тегендә-монда күренгәләгән эшчеләр, элек йорт булган урыннарга кагылган яңа казыклар, күтәрелә башлаган нигезләр киләчәккә ниндидер өмет өсти әле. Авыл яңадан элеккечә яшәп китәр дигән өметне...

Халык та элеккечә, үзләре әйтмешли, сыктамый, ягъни зар еламый инде. Аз еламаганнардыр шул. Хәзер инде үзләрен кулга алганнар, тормышны дәвам итәргә кирәк икәнен аңлаганнар. Булышучылар барда, әлбәттә. Алар хакында бераз соңрак.

«Сүзләрендә торырлар кебек»

Акрын гына берничә ай элек бәла-каза күргән авыл урамы буенча атлыйбыз. Әйе, кайчандыр гөрләгән, яшьнәгән бу сала. Зур булуына да ышанасың. Урамнарның, күңелләрнең киң чагына да...

...Кәлимулла Миңнегәрәев белән элек йорты булган урында басып торабыз. Булган хәлләрне хәзер инде әллә ни хафаланмый сөйли ул. «Йөрәк урынына утырды кебек инде», – ди. Янгын чыккан көнне басуда булган әңгәмәдәшебез. Фермер икән. Ике айдан 60 яшь туласы үзенә.

– Өем зур иде. Бик начар янгын булды бу. Өем дә янды, мал-туарларым да. 10 бозавымның бишесе исән калды. Складымдагы әллә ничә тонна бодай һәм бүтән төр культуралар да янды, – дип сөйли ул. – 5 чакрым ераклыкта гына бер авыл бар. Туганнарыбыз шунда өй бирде, шунда яшибез хәзер. Авылны торгызырлар кебек. Шуңа өмет бар. Татарстанга ышанам мин. Ышандырган кешеләр сүзләрендә торырлар дип уйлыйм.

«Йортым матур иде, хәзер көл инде...»

Ирина Кондина да: «Сыктый-сыктый арыдым инде», – ди. Хәзер яшь арасыннан елмаерга өйрәнгән. Хәер, елмаерга сәбәбе бар. Аңа да йорт салырга булышачаклар. Төзелеш эшләре башланган инде. «15 октябрьгә өлгертәбез», – дип вәгъдә биргән төзүче оешма. Монысы элеккеге йортыннан кечерәк, бер катлы булачак икән. Анысына да шөкер итә инде хәзер хуҗабикә. Яңа салыначак йорты турында сөйли-сөйли, телефоныннан элеккесен – янгын харап иткәнен күрсәтә. Хәзер шул суреткә карап юанса гына инде...

– Йортым матур иде, хәзер көл инде... – дип сөйли ул. – Төзелеш эшләрен үзем дә контрольдә тотам *(көлә)*. Кул кушырып кына утырмыйм. 50 мең сумга төзелеш материаллары алып кайттым, койма булса да уратып куясы килә. Әлегә торыр җирем бар. Көзгә кадәр яшәрлек әле анда.

Ирина апаның мал-туарлары да шактый булган. Атлары исән калган. Ә менә өч бозавын ялкын теле юк иткән. Башка малларын да, мотоблок, мунча, гаражны да ут алган, эте югалган... «Әле яши генә башлаган идем бит... Хәтта мебель дә яңа иде!» – дип уфылдап та ала хуҗабикә.

Эшен дә ташламый. Социаль хезмәткәр булып эшли икән. Улы – хәрби, Төмәндә, кызы авылда мәктәптә эшли. Алар да ташламас. Өч бозау да биргәннәр. Яңа йортта яңа, зур хуҗалык тергезеп җибәрер әле Ирина апа! Вакыт кына кирәк.

«Әни, тончыгам, үләм», – диде»

Фаҗигадә 7 кеше үлүе турында язган идек инде. Үлүчеләрнең берсе – Әнисә Әбдрәшитованың улы. Ул – өченче группа инвалид, аңа нибары 47 яшь була.

– Безне алырга дип туганыбыз килгән иде. Улыма: «Җыен тизрәк!» – дим. «Юк, бернәрсә дә булмаячак. Янгын тиз генә узып китәчәк», – ди бу. Күндерергә дә тырыштым, әрләшеп тә беттек, еладым да... Тыңламады. Курткасын бирде дә: «Китегез!» – диде, – ди кайгыга баткан әни. – Әллә ни ерак та китә алмадык. Улым шалтырата. «Әни, тончыгам, үләм, хуш!» – диде. Улымның курткасы гына калды.

Халык сөйләве буенча, фаҗигадә вафат булган ир-ат идән астына качкан була. Ут өйгә кереп, бөтен җирне камап алгач, качып котылу мөмкин булмый инде. «Егетнең көле генә калган иде», – дип сөйләделәр...

«Авылдан китмим!»

Ринат Сәфәров турында «җир кешесе бу» дияргә тулы хакыбыз бар. Фермер икән ул да. Гомумән, монда игенчелек, терлекчелек белән көн итүчеләр шактый. Шушы авылда туып-үскән, гомере буе шушында яшәгән, гаилә корган Ринат Сәфәров та. Авылны яратуы сөйләшүеннән дә күренә. Бу мәхәббәтне балаларына да сеңдерә алган.

Аларның йорты беренчеләрдән булып яна башлаган.

– Без урман янәшәсендә яши идек. 2000 нче елларда яшь гаиләләргә җир бирәләр иде, шул җирдә салынган йортта яшәдек, – ди ул. – Бик шәп йорт салып чыккан идек. Янгын юк итте инде. Бу җир рәсмиләштерелмәгән була шул. Аны урман фондына тапшыралар. 120 квадрат метрлы йортыбыз, мунча, сарайлар да документлаштырылмаган. Шуңа күрә яңа йортны үз көчем белән салачакмын. Эти йортының урынына салачакбыз.

Беренче көннәрдә ни уйларга да белмәдек, ди Ринат абый. Хәзер инде бераз тынычланганнар. Мәшәкатьләре баштан ашса да, авылдан китү теләге юк. Элек тә булмаган.

– Шәһәрдә торып караган да юк. Олы улым Эдуард та, китмим, ди. Егетем зур булды инде. Авылда яшибез, хуҗалыкны зурайтабыз, ди, – дип горурланып сөйли ата.

Йолдыз авылындагы янгында зыян күргәннәргә йорт салып бирергә ниятләгән дини, иҗтимагый оешмалар, бизнес вәкилләре

✓ Татарстан 18 гаиләгә йорт салып бирәчәк.

✓ «Татнефть» оешмасы Йолдыз авылында үз хисабына 13 йорт төзеп тапшырачак.

✓ Чуашия мөселманнары Диния нәзарәте, мөфтият каршындагы иганәчеләрне җыеп, акча туплап, Йолдыз авылындагы Гариповлар гаиләсенә йорт салып бирәчәк.

✓ Удмуртиядәге дин кардәшләр акчалата, азык-төлекләтә, төзелеш материаллары белән ярдәм иткән. Комплект итеп 64 квадрат метрлы агач йорт эшләп тапшырырга ниятлиләр. Аны авылда яшәүче имамга салачаклар.

✓ «Бөтенроссия татар авыллары» иҗтимагый оешмасы Йолдызда гомере буе колхозда хезмәт куйган 74 яшьлек абзыйга йорт җиткерергә ярдәм итәчәк.

✓ Түбән Варта «Мирас» иҗтимагый мөхтәрияте авылдагы укытучыга йорт салачак.

✓ Самарадан бер төркем эшмәкәрләр, иҗтимагый оешма вәкилләре Фәтхуллиннар гаиләсенә булышачак. Йортның нигезе инде салынган.

✓ Россия мөселманнары Диния нәзарәте Йолдыз авылындагы Мөхәммәтнәбиев гаиләсенә йорт төзеп бирәчәк. Бу гаиләдә 3 бала үсә, лаеклы ялда булган 62 яшьлек әбиләре дә бар. Гаилә башлыгы инвалид та икән әле.

Крестьян-фермер хуҗалыгы тоткан кешегә бер юаныч бар инде: Татарстан исеменнән аңа трактор бүләк иткәннәр. Табигать тә күчтәнәчен жәлләмәсен иде инде хәзер: Ринат абый яңгыр тели.

Сер бирмәс Сәхибә

Юлыбызга **Людмила Шәмсетдинова** очрады. Кулына бер чәнечке тоткан. Янган өеннән калган булса кирәк... Ул ялгызы гына яши. Бу авылның иң өлкән кешеләренең берсе ул. Хәер, безгә яшен әйтмәде. Җор телле булуы, активлыгы үз яшен бирергә юл куймый. Берүзе генә булуына карамастан, 13 баш мал асрый!

– Йолдыз барлыкка килгәннән бирле салынган йорт иде бу. Монда минем ата-бабалар яшәгән, торган. Йортка берни булмаган. Түбәләр эшләткән идем. Йортым ямьле булган иде. Зиратта яткан туганнар да куанып ятканнардыр... Әмма менә бит ничек килеп чыкты. Без теләгән түгел, Аллаһы Тәгалә шулай кушкан, димәк... – ди ул.

Янгын чыккан көнне тышта эшләп йөргән була әңгәмәдәшебез. Күршеләре хәбәр иткәч, тиз генә документ, оек, кофта, ыштан ала да чыгып китә. Малларын яланга куып чыгара. Күршеләре машинага утыртып, читкәрәк алып китә. «Бу вакытта инде урамны кап-кара төтен каплаган иде», – ди ул.

Люда апага хәзер вакытлыча яшәп торырга вагон биргәннәр. Мал-туарлардан ерак җиргә күченеп китә алмыйм, күз-колак булу кирәк, ди. Агач материаллар белән дә булышканнар. Дәүләт биргән акчага койма да корып куйган. «Мин ул акчаны юкка-барга тотмадым, эчеп тә бетермәдем. Кыйбатлы материал сатып алып булмады инде. Шулай да коймалы булдым», – ди ул.

Вагондагы яшәү шартларыннан да зарланмый. Гомумән, зар ишетмәссең бу ападан! «Плитә бар, утын бар. Хәзер аш пешереп алам. Кибетләр дә бар. Әмма монда барысы да кыйбат», – ди ул. Әңгәмәдәшебезнең пенсиясе – 9 мең.

Людмила апаның мулла кушкан исеме Сәхибә икән. Авылдагылар Людмила Салаховна дип йөртә икән үзен. «Совет чорында Люда дип дәшкәннәренә өйрәнгән инде», – ди. Кем булып кына эшләмәгән үз гомерендә! Кияүгә чыкмаган, балалары юк. Үзен эшкә багышлаган, хезмәттән курыкмаган. «Хәзер дә үземне эш белән чыбыркылап торам мин», – ди ул.

Күпләп мал-туар тоткан Люда апага суыткыч кирәк. Ни өчен бирмәгәннәрен дә белми. «Сиңа өй салалар, шуңа күрә сиңа юк», – дигәннәр аңа.

– Суыткыч иң элек маллары булган кешеләргә кирәк инде ул, – ди үзе...

Людмила апаны тагын менә нәрсә борчый:

– Бу хәлләрдән соң халык бүлгәләнә башлады шул... Сиңа, миңа, диюләр китте... Барысы да үзгәрде... Койма куйганыма да көнләшүчеләр булды әле, – дип хафалана ул.

Кешегә бар, миңа юк?

Авылның Беренче май урамындагы йортсыз-нисез басып калган капка җәлеп итте. Әнисә һәм Наил Мәүлетовлар «йорты» икән бу. Янгын барысын да юк иткән, дияр идек, әнә шул капка калган да, балалар өчен дигән мәйданчык калган. Наил абый Мәүлетов балтаны да, мәсьәләне дә үз кулына алган инде. Йортны үз көчләре белән торгызырга гына кала аларга, чөнки теркәлү урыннары Екатеринбургта икән. Дәүләттән бирелә торган сертификат аларга эләкми, димәк. Шулай да 500 мең сумлык матди ярдәм тәтегән. Әмма бу сумма, фаҗига ясыйлыгында караганда, берни түгел инде.

– Үзебез төзербез инде, – диде Наил абый. – Зурлыгын сигезгә сигез итеп эшләрбез дип торабыз.

– Сертификат 500 мең сумлык кына булгач, йорт төзүче оешмалар безнең белән килешү төзергә ашкынмый, – дип сүзгә кушыла аның хатыны. – Материалларны үзебез алачакбыз инде. Нишлик... Акча юк. Балалар «булышырбыз» ди инде. Әлегә без йорт яллап торабыз. Анысына да акча кирәк бит...

Халыкка – ФАП, балага – рюкзак, яшьләргә – никах

Бу көннәрдә Йолдыз авылында Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев һәм аның җитәкчелегендәге делегация дә эшләде. Милли Шура рәисенең бу җирләргә өченче килүе инде. Ул ким дигәндә ай саен биргә килеп, вазгыять белән танышып барачагын әйткән иде.

Бу юлы авылда яңа фельдшер-акушерлык пунктын ачтылар. Медицина ярдәме алырдай урынга ихтыяҗ чынлап та бар иде. ФАП хезмәтеннән 500ләп кеше файдалана алачак. ФАПны җиһазландыруга 1,3 млн сум тирәсе акча тотылган.

Балалар да читтә калмады. Йолдыз авылы урта мәктәбенә йөрүче балаларга Бөтендөнья татар конгрессы рюкзак, мәктәп формасы һәм велосипед бүләк итте. Әлеге мәктәпкә 68 бала йөри.

Милли Шураның күчмә утырышы да Йолдыз авылында үтте. Мәдәният йортында оештырылган җыенда Васил Шәйхразыев: «Май ае белән чагыштырганда хәзер авыл – җир белән күк арасы. Безнең хәзергә бурычыбыз – кешеләрне йортлы итү. Көзгә, Курган өлкәсе губернаторын да чакырып, зурлап өй туйларын оештырырбыз. Авылны торгызу символы итеп сквер да ясарбыз», – дип куандырды авыл халкын.

Бу көнне Йолдызның яшәве дәвам итәчәген дәлилләгән тагын бер вакыйга да булды. Фәткуллиннар гаиләсенә килен төште! Дөрес, тулы канлы йортка түгел, әлегә күтәрелеп кенә килә торган нигезгә. Яшьләргә – Эрик белән Камиллага никахны Россиянең Азия өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Нәфигулла хәзрәт Аширов укыды. Никахны кичектереп торырга да карар кылган булганнар, әмма мәҗлес оештыру эшен Бөтендөнья татар конгрессы үз өстенә алган. Шулай итеп, көл өстендә яңа татар гаиләсе барлыкка килде, нигезгә мәхәббәт салынды. Хәерлесе булсын!

Соңгы сүз урынына

Халык өметен өзми. Бу өметне өзәргә дә ярамый. Әле ярдәм кирәк! Бюрократия, кәгазь боткасы, законда болай кушылган дигән сүзләр көтми халык. Аның яшисе килә. Бу теләк бик зур. Кешечә итеп, элеккечә итеп. Өлгерәсе генә иде. Җитәкчелекнең, көз айларында өй туйларын гөрләтербез, диюләренә дә ышанасы иде.

Сан

- Йолдызда йорт торгызу яисә сатып алу өчен барлыгы **178** сертификат бирелгән. Йорт салырга уйлаганнар өчен өстәмә рәвештә **700** мең сум акча биреләчәк.
- Йолдыз авылында **46** йорт төзелеше башланган.
- Йолдыз халкы беренче чираттагы ихтыяҗлары өчен **10** мең сум һәм янгында зыян күргән милек өчен **50** мең сум күләмендә түләүләр алган.
- Татарстаннан бу авылга барлыгы **11** фура гуманитар йөк озатылган.
- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы ярдәм йөзеннән Йолдызда яшәүчеләргә **7** техника тапшырган.
- Йолдыз авылыннан **30** бала Актаныштагы «Бүләк» лагеренда ял иткән.

Рафит Муллаянов

Авыл капкасы

Бәрәңгеләр чәчәк атмады...

Бәрәңге утыртканга ике ай ярымлап вакыт үтте. Быел алар, башка еллардагы кебек, шаулап чәчәк атмады. Июнь уртасындагы кыраулар төшкәндә чәчәккә бөреләнгәннәр иде, бик сирәкләре генә ачылды. Күрәсең, бөреләренә салкын тиде.

Дөрес, бер дә атмадылар түгел, бүгенгә кадәр бәрән-сәрән чәчәкләре күренә. Башка елларда бит бөтен бакча берьюлы чәчәк ата (бер генә төрле сорт үстерү нәтиҗәсе), ун-унбишәр көн күз явын алырлык булып, ап-ак булып балкып утыра иде. Бер бездә генә түгел, башка авылдашларда, башка урыннарда да шул ук хәл. Район үзәгендә яшәүче туганнарымда ике урамның бәрәңге бакчалары бер-берсенә кушылып, терәлеп тора. «Бары бер бакча бәрәңгеләре элеккечә чәчәк атты, югыйсә беребезнекенә дә кырау зыян салмаган иде», – ди туганым. Танышлардан сораштыра башлагач, аларның кайберләре моңа игътибар да итмәгән булып чыкты: «Әллә тагын...» – диючеләр дә, «Андый еллар булды бит инде ул», – дигән битарафлар да булды. Авылда яшәп, ничек инде бәрәңге чәчәгенә битараф калып була, шомырт, сирень кебек хуш ис бөркемәсә дә, табигатьнең тагын бер иң гүзәл чәчкәсе бит алар. Утыртканнан шул чорны көтә башлыйсың лабаса. Өстәвенә белгечләр, бәрәңге чәчәк аткан чорда бүлбеләр формалаша, калган чакта шулар үсә, дип аңлата.

Дөрес, хәзер авыл кешесе дә бәрәңгегә генә карап утырмый. Элеке кебек күп ашамлык, төп ризык түгел. Малларга да булса – ярый, булмаса, куркыныч түгел, дигән карашта торабыз. Бакчалар да шул сәбәпле елдан-ел кими. Әмма ни генә дисәк тә, бәрәңге казыганда уңышы мул булса рәхәт, шуңа да үссеннәр дип тырышабыз.

Бездән бер атна алдан утырткан авылдашларыбыз: «Кырау сукканда бәрәңгеләр чәчәк ата башлаган иде инде, чәчәкләре дә, бөреләре дә коелып бетте. Сабаклары көеп утырды. Яңгырлардан соң яшәреп, ныгып киттеләр. Беркөн тавыклар бакчага чыккан, берничә төп бәрәңгене тузгыткан. Күреп, үзебез дә шаккаттык, каз йомыркасы зурлыгындагы бәрәңгеләр дә бар иде. Уңыш була икән дип сөендек», – дип, күңелгә җылы кертте.

Кайчандыр бәрәңге үстерергә махсуслашкан, бүген инде Балтач районында бердәнбер бәрәңге үстерүче «Татарстан» хуҗалыгының баш агрономы Фирдус Хәкимов белән дә шул турыда сөйләштек.

– Безнең басулар да берьюлы, күпләп чәчәк атмады. Бәрәңге уңышына зыяны юк инде аның. Башка шартлары уңай килү кирәк. Алданрак утырткан участокка кырау шактый зыян салган иде. Яфрактан микроэлементлар белән тукландыру үз эшен эшләде, бик тиз тернәкләнеп киттеләр. Бәрәңгене бит хәзер, элекке кебек, утырттым да эше бетте түгел, бик нык тәрбияләргә кирәк. Шунсыз мул уңыш алам димә. Быел 94 гектарда утырттык, дүрт төрле сорт игәбез, ел саен яңа сортлар да сыныйбыз. Мәшәкатьле, чыгымлы булса да, бәрәңге – иң рентабельле культураларның берсе, аннан баш тартырга җыенмыйбыз, – ди Фирдус.

34 ел агроном булып эшләгәндә бәрәңге юнәлеше өчен җаваплы булган, лаеклы ялга чыккач, үзе әйткәндәй, «эшсез дип әйтмәсеннәр өчен генә» бәрәңге үстерү белән мавыккан Балтач районының Нөнәгәр авылында яшәүче Нотфулла абый Гарипов та, бәрәңгеләрнең чәчәк атмавы уңышка тискәре йогынты ясамый, ди. «Бөтенләй чәчәк атмый торган сортлар да бар хәзер. Кайбер белгечләр бәрәңге чәчәген өзеп атарга да куша. Соңгысы – берничә төп бәрәңге үстергән кешеләр өчен генә мөмкин эш. Без үзебез һәр елны күп төрле сорт утыртабыз. Быел да егермедән артык. Беренче майда иртә өлгерә торган бәрәңге утырткан идек, 9 июньдә чәчәк атты һәм кырау сукты. Бәрәңгеләр тернәкләнде, әмма җитәрлек дым булмагач, уңышы без теләгәнчә үк булмады. Быел Чиләбедән «Гамлет» дигән сортлы бәрәңге алдырган идем, 10 данә бәрәңге инде ул. Мин аны, күзеннән бүлгәләп, 33 төп итеп утырттым. Менә алар шау чәчәк атты, башка сортлар чәчәк атмады. Салкыннар да роль уйнагандыр, дым җитмәү дә... Кортлар да чамасыз күп бит быел... Корылык булмаса да, бездә дә шартлар бәрәңге өчен бик үк кулай түгел. Уңышы кимрәк булса да, бәрәңгесез калмабыз», – ди ул.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

17 июль | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.00 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». Телесериал 16+
13.00 «Ком сәгате» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Туган авылым» 12+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
00.00 «Соотечественники». Башир Рамеев. Творец советских компьютеров 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Таяну ноктасы» 16+
01.15 «КВН РТ – 2022» 16+
02.05 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
02.30 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.00 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Яралы язмышлар». Фәнис Яруллин 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык артисты Рөстәм Маликов турында телеочерк 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Әмирхан Еники турында телеочерк (субтитрлы) 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Ватандашлар» 16+
02.35 «Таяну ноктасы» 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык артисты Рөстәм Маликов турында телеочерк 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Агния Дитковските, Александр Устюгов. «МИССИЯ «АМЕТИСТ» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Алексей Герман. Трудно быть с Богом» 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
02.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
02.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Анекдоты» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Анекдоты» 16+
03.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Сергей Маковецкий, Александр Яценко, Татьяна Лялина, Виктор Сухоруков, Артур Иванов, Мария Шумакова, Константин Крюков, Артём Ткаченко, Мария Палей. «ГРОЗНЫЙ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Евгений Сидихин, Лариса Шахворостова, Александр Самойленко. «СЧАСТЬЕ НЕ ЗА ГОРАМИ» 12+
23.30 Сергей Маковецкий, Евгений Ткачук, Дарья Урсуляк. «ТИХИЙ ДОН» 12+
01.10 XXXII Международный фестиваль «Славянский базар в Витебске».
02.45 Анастасия Веденская, Сергей Губанов. «РАЯ ЗНАЕТ ВСЁ!» 12+

МАТЧ ТВ

Профилактика на канале с 6.00 до 11.00 часов
11.00, 12.55, 14.55, 16.50, 21.30 Новости
11.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
11.25 Профессиональный бокс. Денис Лебедев против Павла Колодзея. Трансляция из Москвы 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.25 «Кто кого?» 12+
15.00 Автоспорт. Дрэг-рейсинг. Фестиваль Суперкаров UNLIM Fest 0+
15.30 «Громко». Прямой эфир
16.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Тюмень» – «Химки» (Московская область). Прямая трансляция
19.00, 21.35, 00.35 Все на Матч! Прямой эфир
19.25 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Черноморец» (Новороссийск) – «Алания» (Владикавказ). Прямая трансляция
22.15 «НА ПРЕДЕЛЕ: ИСТОРИЯ ЛЕГЕНДЫ» 12+
01.25 «Спортивный век» 12+
02.25 «Магия большого спорта» 12+
02.55 Новости 0+
03.00 Чемпионат мира по водным видам спорта. Прыжки в воду. Трансляция из Японии 0+

НТВ

05.25 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.10 «Мои университеты. Будущее за настоящим» 6+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00, 00.00 Детектив «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ» (S) 16+
00.20 «Основано на реальных событиях». «КОРОЛЕВА МАФИИ» 16+
01.15 Игорь Лифанов в детективном сериале «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.55 «Тест на отцовство» 16+
11.10 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». «Почерк судьбы» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Преступления страсти» 16+
19.00 «ЦЫГАНКА». 1-я – 5-я серии 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.15 «Порча» 16+
01.40 «Знахарка» 16+
02.05 «Верну любимого» 16+
02.35 «Голоса ушедших душ» 16+
03.00 «ПАРФЮМЕРША». 1-я – 4-я серии 16+

ЗВЕЗДА

05.55 «ИЗ ПЛАМЯ И СВЕТА...» Телесериал. 3-я – 5-я серии 16+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
11.00, 03.05 «БЕЗОТЦОВЩИНА» 12+
13.25 «ЧКАЛОВ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
18.00 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Документальный сериал. «На Южном фланге. 1941 год» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам». Премьера! 16+
20.10 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Ужас за колючей проволокой» 16+
22.45 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.15 «МЕРСЕДЕС» УХОДИТ ОТ ПОГОНИ» 12+
00.55 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ-2». Телесериал. 1-я – 3-я серии 16+
04.35 «ЧКАЛОВ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

18 июль | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+
09.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «ШИРОКА РЕКА». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30 «Гаилә учагы» 16+
12.00, 22.00 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». Телесериал 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.30 Новости Татарстана 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Соотечественники» 16+
16.30 «Болгар радиосы» концерты 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Туган авылым» 12+
20.15 «Кучтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Династия русских учителей 6+
00.50 «Соотечественники». Хотите, я вам почитаю… В.Качалов 16+
01.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телевизион нәфис фильм 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Рәфкать Бикчәнтәев турында телеочерк (субтитрлы) 16+
18.20 «Җырлыйк әле!» 12+
19.15 «Татар әдәбияты дәресләре» 6+
20.00 «Халкым минем» 12+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
22.15 «Йөрәктән – йөрәккә». Габделфәрт Шәрәфиев турында телеочерк 16+
23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
00.15 «Татар әдәбияты дәресләре» 6+
01.05 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «МИССИЯ «АМЕТИСТ». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Владимир Маяковский. Третий лишний» 12+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем» 16+
02.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
03.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
04.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Сергей Маковецкий, Александр Яценко, Татьяна Лялина. «ГРОЗНЫЙ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «СЧАСТЬЕ НЕ ЗА ГОРАМИ» 12+
23.30 Сергей Маковецкий, Евгений Ткачук, Дарья Урсуляк, Тимофей Трибунцев, Никита Ефремов, Александр Яценко. «ТИХИЙ ДОН» 12+
00.20 Торжественная церемония закрытия XXXII Международного фестиваля «Славянский базар в Витебске».
01.20 «РАЯ ЗНАЕТ ВСЁ!» 12+
03.05 «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Кто кого?» 12+
06.30 «Лето. Евро. 2008» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 16.55, 18.55, 21.30 Новости
07.05, 15.30, 19.00, 21.35, 00.35 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25, 01.25 «Спортивный век» 12+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Стипе Миочич против Даниэля Кормье. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 Автоспорт. Ралли-рейд «Шёлковый путь» 0+
16.30, 17.00 «НА ПРЕДЕЛЕ: ИСТОРИЯ ЛЕГЕНДЫ» 12+
19.30 «Ярцев. Вечное сияние». Документальный фильм 12+
20.30 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Лучшие голы сезона 0+
22.15 «КОРОЛЕВСКИЙ ГАМБИТ» 16+
02.25 Автоспорт. G-Drive Российская серия кольцевых гонок. Трансляция из Санкт-Петербурга 0+
02.55 Новости 0+
03.00 Чемпионат мира по водным видам спорта. Прыжки в воду. Трансляция из Японии 0+
04.30 «Неизвестный спорт. На что уходит детство?» 12+
05.30 «Как это было на самом деле» 12+

НТВ

05.20 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.15 «Мои университеты. Будущее за настоящим» 6+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00, 00.00 Детектив «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ» (S) 16+
00.20 «Основано на реальных событиях». «КОРОЛЕВА МАФИИ» 16+
01.20 «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.55 «Тест на отцовство» 16+
11.10 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». «Экспресс-приворот» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Преступления страсти» 16+
19.00 «ЦЫГАНКА». 6-я – 10-я серии 16+
00.20 «Понять. Простить» 16+
01.15 «Порча» 16+
01.40 «Знахарка» 16+
02.05 «Верну любимого» 16+
02.35 «Голоса ушедших душ» 16+
03.00 «ПАРФЮМЕРША». 5-я – 8-я серии 16+
05.50 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

06.20 «ЧКАЛОВ». Телесериал. 3-я и 4-я серии 16+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «КАРЬЕРА ДИМЫ ГОРИНА» 12+
13.25 «ЧКАЛОВ». Телесериал. 5-я – 8-я серии 16+
18.00 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Документальный сериал. «Битва за Великие Луки» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого». «Тайны Ледового побоища. Почему ошибаются историки?» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ТАЕЖНАЯ ПОВЕСТЬ» 12+
01.15 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ-2». Телесериал. 4-я – 6-я серии 16+
03.25 «Алексей Маресьев. Судьба настоящего человека». Документальный фильм 12+
04.15 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
04.35 «ЧКАЛОВ». Телесериал. 5-я и 6-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры **Кузюров** Равил Әфраим улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасы үзәкләштерелгән дини оешмасы – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте баш казые **Фазлыев** Җәлил Васыйл улы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Машина төзү өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Казан моторлар төзү-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте токаре **Герасимов** Николай Александровичка Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «СМП-Нефтегаз» акционер җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе **Комаров** Фоат Фәһим улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Эллада» төзелеш компаниясе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры **Зуев** Андрей Анатольевичка, «АК БАРС Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры урынбасары **Король** Александр Евгеньевичка, «Домкор Строй» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең санитария-техник системалары һәм җиһазлары монтажчысы **Лотфуллин** Гамир Өлфәт улына, «Татарстан Республикасының баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры урынбасары **Рәшитов** Илдар Мирхәйдәр улына, «КАСТАМОНУ ИНТЕГРЕЙТЕД ВУД ИНДАСТРИ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең әйдәүче инженер-төзүчесе **Сабитов** Алмаз Әнәс улына, «Татавтодор» акционер җәмгыятенең Саба филиалы төзелеш һәм монтаж эшләре мастеры **Сабуров** Илнур Зиннур улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе спортның ишкәкле төрләре буенча федераль спорт-тренировка үзәгенең спорт буенча инструкторы **Гоголин** Владимир Александровичка, «Россия җыелма спорт командаларын әзерләү үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Регби буенча Россия Федерациясе җыелма спорт командасы өлкән тренеры, Казан шәһәре Киров районының «Заман» 189 номерлы күппрофильле гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең өстәмә белем бирү педагогы (берьюлы ике урында эшләүче) **Калашкин** Павел Александровичка, «Татарстан Республикасының чирәмдә хоккей федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Кирьянова** Людмила Васильевнага, «Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең «Спортның су төрләре сарае» өйрәтү-спорт комплексы директорының гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары **Кормушин** Владимир Ивановичка, «Россия җыелма командаларының спорт әзерлеге үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе Россия Федерациясенең көрәш буенча җыелма спорт командасы баш тренеры, «Россия көрәш федерациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасы вице-президенты **Ногманов** Равил Уел улына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесенең спортның җәйге төрләре бүлеге башлыгы **Скокова** Елена Владимировнага, «Татнефть – Ак Барс» спорт-коммерциячел предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең инструктор-методистлар төркеме йөзү бассейны инструкторы-методисты **Ушаков** Евгений Михайловичка **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

УЕН ЭШ ТҮГЕЛ

Көн тудымы – чир! Әле кайчан гына холера турындагы хәбәрләр тынычлыгыбызны алган иде. Узган атнада исә Россиядә менингит тарала башлавы билгеле булды. Исеме билгеле бер маркетплейсның товарларны аралау үзәгендә эшләүче җиде кешегә шундый диагноз куелган. Роспотребнадзор идарәсе белгечләре, башка төбәкләргә дә уяулыкны югалтырга ярамый, дип кисәтә. Менингит турында без нәрсәләр белеп торырга тиеш?

Табиб-терапевт, невролог Эльвина ХАЛИТОВА шул соравыбызга ачыклык кертте.

Менингит – баш һәм арка мие тышчасы ялкынсынудан гыйбарәт. Вакытында дәваламасаң, ялкынсыну баш мие тукымасына ук күчәргә мөмкин. Бу исә бик куркыныч. Баш мие тукымасында ялкынсыну башланса, кеше даими рәвештә баш авыртудан тилмерә. Андый чакта авыртуны басу бик читен. Һава торышы үзгәргәндә баш авырту тагын да көчәя. Моннан тыш кешене паралич сугарга, ул чукракланырга, нерв күзәнәкләре зарарланырга да мөмкин. Баш мие тукымасы ялкынсынган балаларның үсешендә тоткарлыклар да башлана ала. Дөрес диагноз куелып, вакытында дәвалый башласаң, менингит йоктырган кеше тиз арада аякка баса. Аннан соң өзлегүләр дә күзәтелми.

Менингитның вируслы, бактериаль, гөмбәчел, катнаш һәм паразитлы төрләре билгеле. Араларында бактериаль төре иң очрый. Ул иң куркынычы санала. Аны менингококк бактериясе китереп чыгара. Менингитның әлеге төре кисәк кенә башлана һәм тиз арада көчәя. Кешенең тән температурасы күтәрелә, калтырата башлый. Берничә көннән тәнгә тимгелләр чыга. Кеше баш әйләнүдән,

vk.com

муен мускуллары авыртудан да зарланырга мөмкин. Менингит вакытында яктылыкка карау да җәфага әверелә. Авыру һава юлы белән күчә.

Менингиттан фәкать вакцина ярдәмендә генә сакланып була. Ул шушы авыруны йоктыручы белән аралашкан кешеләргә генә түгел, профилактика өчен дә ясала. Ул – бик җитди авыру. Менингитка балалар ешрак бирешә. Әлеге чир сабыйлар арасында өлкәннәр белән чагыштырганда 25 тапкыр ешрак очрый. Бала кечерәк булган саен менингитны да авырданрак уздыра. Шуңа күрә ике яше тулмаган балалар арасында әлеге чирдән үлем-китем очраклары аеруча күп теркәлә.

Менингит билгеләре күзәтелгәндә кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Аны бары тик хастаханәдә генә дәвалап була. Чирдән өй шартларында, халык медицинасы ысуллары ярдәмендә генә котылырга маташу бик аяныч тәмамланырга мөмкин. Менингитны антибиотиклар ярдәмендә дәвалыйлар. Хастаханәдә ятып чыкканнан соң кеше тернәкләнү өчен өенә кайтарыла. Бу чорда да аңа даими рәвештә табибка күренеп торырга кирәк булачак. Менингит белән авырып терелгән кеше ярты ел дәвамында – ай саен, аннары өч айга бер тапкыр табибка барырга тиеш. Ник дигәндә, бу җитди чирдән соң ахыргача тернәкләнеп бетү өчен бик күп вакыт таләп ителә. Андый чакта кеше физик кына түгел, психик ярдәмгә дә мохтаҗ була.

Кыш көне башыңа кием йөрмәсәң, менингит башланачак, дигән фикер яши. Әмма бу мәкерле чирдән башлык кына саклап кала алмый. Ник дигәндә, менингит китереп чыгаручы микроорганизмнар адым саен. Дөрес, башка кимичә йөргән кеше туңарга, бу исә иммунитетны какшатырга мөмкин. Бу исә, үз чиратында, менингит йоктыру өчен менә дигән җирлек.

Менингит һава юлы белән генә түгел, пычрак куллар, юылмаган савыт-саба аша да кешедән кешегә йога ала. Аны юылмаган яшелчә, җиләк-җимеш ашау аркасында да эләктерергә мөмкин. Менингит хәтта заказ белән кайтартылган посылка аша да йога ала.

МЕНИНГИТТАН САКЛАНУ ӨЧЕН КИҢӘШЛӘР

✓ Кеше күп җыелган урыннарда битлек киеп йөрегез;
✓ менингит белән авырган кешеләр белән аралашуны кичектереп торыгыз, аралашкан очракта чирне кисәтү өчен махсус дарулар эчеп кую зыян итмәс;
✓ йорт-җирне һәрчак чисталыкта тотыгыз;
✓ ашар алдыннан кулларны яхшылап юарга, яшелчә, җиләк-җимешләрне юып ашарга онытмагыз;
✓ дөрес туклану, витаминнар эчү хисабына иммунитетны ныгыту ягын да кайгыртыгыз;
✓ менингит йоктырмыйм дисәң, торгын сулыкларда су коенырга да ярамый.
✓ менингитка каршы вакцина ясатырга онытмагыз.

Саклап куй!

Кан тамырлары киңәюдән

ПОМИДОР. Пешкән помидорны кисәкләп турагыз да киңәйгән аяк тамырларына каплап, чеметкәли башлаганчы тотыгыз. Помидор кисәкләрен алгач, аякларны салкын су белән юарга онытмагыз. Дәвалану процедурасын тамыр зәңгәрлеге беткәнче кабатларга кирәк.

ӘРЕМ. Бер уч төелгән әрем яфрагы белән орлыгын ярты литр оеган сөткә салып болгатыгыз. Шул боламыкны 3–4 кат марлядан ясалган салфеткага сылап, аякның киңәйгән тамырларына каплагыз. Өстенә полиэтилен ябыгыз да, аякны кечкенә мендәргә сузып, ярты сәгать утырыгыз.

Үзем сынадым

Мунча ябыктыра икән

«Мунча ябыктыра» дигән сүзләрнең хаклыгына үз мисалымда инандым. 100 грамм балга 100 грамм тоз, берәр аш кашыгы сода белән спирт салып болгатам да шул катнашманы тәннең ябыктырасы килгән өлешләренә сылыйм. Анналы шул урыннарны полиэтилен пакет белән чорнап, 10–15 минут парланып утырам. Шул рәвешле бер айда өч килограмм авырлыктан котылдым.

Динара ХАЛИТОВА. Арча

Табигать даруханәсе

ТӘМЛЕ ДӘ, ШИФАЛЫ ДА

Бакча күрке булып утырган кура җиләгенең сәламәтлеккә шифасы әйтеп бетергесез. Анда глюкоза һәм фруктоза, A, C, B, B_1 B_2, PP, E витаминнары бар. Ул тимер, калий тозлары, каротин антоцианнар, катехиннар, аксым, клетчаткага да бай. Анда холестерин ясалуга һәм склерозга каршы тора торган бета-ситостерин да бар. Җиләк составындагы фолий, алма, лимон, шәраб, гәрәбә кислоталары ашаган ризыкны эшкәртергә булыша. Әгәр ашказаныңның әчелеге түбән булса, кура җиләге аны да тулыландыра. Әлеге бакча нигъмәте эчәк авырулары барлыкка килү ихтималын да кимәтә.

Кура җиләген нефрит, подагра, бөер ташы авыруыннан интеккән кешеләргә ашарга ярамый. Ул аллергия дә китереп чыгарырга мөмкин.

Кура җиләгеннән шифалы рецептлар

ГЕРПЕСТАН. Кура җиләге сабакларын ваклагыз, алар кызылсу төстә булса яхшырак. 1 аш кашыгы сабакка ярты литр кайнар су салыгыз. Өстен каплагыз һәм 2 сәгать төнәтегез. Сөзеп, көненә 5 тапкыр яртышар стакан эчәргә кирәк.
ЭЧ КИТҮДӘН. Иң элек 2 аш кашыгы кура җиләге яфракларына ярты литр кайнар су салырга кирәк. Шуны 2 сәгать төнәткәннән соң, көненә 4 тапкыр ашаганчы 100 мл эчәргә кирәк.
АНГИНАДАН. 4 чәй кашыгы җиләккә 2 стакан кайнар су салырга да, өстен каплап, 3 сәгать төнәтергә кирәк. Төнәтмәне җылы килеш көненә 4 тапкыр ярты стакан эчәсе булачак.
БЕТЧӘЛӘРДӘН. Кура җиләге яфракларының согын сыгып, 1:3 исәбендә атланмай салып болгатыгыз. Шуны биткә сөртеп, 15–20 минут тотыгыз, җылы су белән юып алыгыз.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ТӘМЛЕ БУЛСЫН ПОМИДОР!

Бакчада – җиләк-җимеш, яшелчә, урманда җиләк һәм гөмбә өлгерде. Табигать нигъмәтләре белән туйганчы сыйлангач, алардан кышка төрледән-төрле «тәмлүшкә»ләр әзерли башлыйбыз. Кыяр-помидор тозлау, кайнатма ясау рецептларын төрлечә «кыландырып» карыйбыз. Тик аларны тәмлерәк, үзенчәлерәк итү, бозмыйча саклау кагыйдәләрен белеп тору да зыян итмәс.

Бакчачы һәм аш-су остасы Дания ГЫЙЛЬМИЕВА киңәшләрен тәкъдим итәбез.

vk.com

Төп кагыйдә

Банкаларны горчица порошогы яки чәй содасы белән юудан да яхшысы юк. Шуннан чиста банкаларны газ мичендә 5 минут чамасы парландырып алырга гына кала. Ә инде «заготовка» әзерләү өчен яшелчә яки башка әйбернең сыйфатлысын гына сайлап алуны аңлатып торасы юк. Бу кагыйдәне үтәгәндә, банкалар беркайчан да «атмаячак».

Яшелчә тозлау

Банкадагы кыяр, ямь-яшел төсен саклап, кетердәп торсын өчен, башта аны салкын суда 2–3 сәгать тотарга кирәк. Шуннан соң гына банкаларга тутырып, яшелчәдәге барлык микроблар һәм бактерияләр юкка чыксын өчен, кайнап торган су кояргa. Аннан инде тозлык салырга.

Банка эчендә күгәрек барлыкка килмәсен өчен, угыч аша уып, бераз гына керән өстәргә мөмкин. Тозга килгәндә, гадәттәгесен – эресен (йодлысын түгел) кулланырга. Юкса тозлыкның болгануы бар.

Помидорга имән, карлыган, чия яфраклары үзенчәлекле тәм кертә. Томатны, ярылып китмәсен өчен, теш чистарткыч таякчык белән тишкәләргә кирәк. Һәр банкага бераз гына карлыган (яфрагын түгел, ә җиләкләрен) салырга мөмкин. Помидорга әчкелтем тәм биреп, тозлыгын бик матур төскә кертә ул. Банка «атмасын» өчен горчица орлыклары өстәргә була.

Яшелчә тозлаганда гадәти аш серкәсе урынына алма яки виноград серкәсе кулланыгыз – хуш исе һәм тәме күпкә яхшырак булачак!

Кайнатма һәм компот

Беренчедән, вареньены бары тик эмальле савытта гына кайнатырга тырышыгыз. Җиләге изелмәсен, сиробы үтә күренмәле булсын өчен салмак кына утта өч тапкыр 20–25 минут чамасы кайнатып алыгыз.

Җиләк һәм алма кайнатмасына бераз гына лимон кабыгы, дарчин (корица) яки ваниль өстәргә мөмкин – бик тәмле булачак! Грушаныкына – 50 грамм коньяк, крыжовникныкына лимон кисәкләре салган очракта ашап туйгысыз варенье килеп чыгачак.

Әчкелтем җимешләрдән (әйтик, чиядән) ясалган компотка, шикәр комыннан тыш, берәр чеметем тоз салып караганыгыз юкмы?! Компотыгыз искитмәле дәрәҗәдә тәмле булачак! Ә бакча җиләге, төче чия компотына бераз гына лимон кислотасы һәм берничә бөтнек яфрагы өстәп җибәрүдән дә яхшысы юк.

Салат

Аны пешерү өчен калынрак төпле кәстрүл (тирән эчле савыт) кирәк. Озын тоткычлы агач яки пластик кашык белән болгату әйбәтрәк.

Ташкабактан бик тәмле икра ясыйм, дисәгез, яшелчәне башта бераз кыздырып, шуннан соң, алма, сарымсак, башлы суган, татлы борыч (иттарткыч аша чыгарырга яки ваграк итеп турарга мөмкин) өстәп, сүрән утта пешереп алыгыз.

Салатка яшел тәмләткечләрнең (укроп, петрушка, базилик, майоран, тимьян, кинза) кипкәнен салу әйбәтрәк. Болай эшләгәндә, аны озаграк саклап булачак.

Лечога килгәндә, тәмле һәм төсе матур булсын өчен озак пешермәскә. Татлы борыч изелмәскә тиеш.

Чөгендер салатының (угыч аша уып) помидор белән ясаганда тәмлерәк килеп чыгуын беләсезме?! Аны борщка өстәргә дә, болай ашарга да мөмкин. Кайбер салатларга дөге, борчак, фасоль өстәргә була. Мондый ризыкны эштә яки табигатькә чыкканда куллану бик уңайлы. Гарниры-ние бергә!

Гөмбә

Гөмбә банкаларына керән тамыры һәм яфрагын салган очракта, тәмле дә булачак, озак та сакланачак. Баллы гөмбәне (опята) исә томат соусында маринадлау әйбәт.

Җирән (рыжик), ал гөмбәләрне (сыроежка), гөреҗдәне сельдерей, кориандр, карлыган яфраклары белән тозлыйлар.

Шампиньонны маринадлаганда, кайнап чыккач, тозлыкка салып, 7–10 минут тотарга кирәк. Аш серкәсе урынына лимон согы белән алма серкәсе (1:1 нисбәтендә) куллану әйбәтрәк. Гөмбәдән икра ясаганда, бер кәстрүлгә төрле гөмбә салып пешерергә, маринадына кишер, суган, тәмләткечләр өстәргә. Бәлеш, бөккән һәм пицца өчен менә дигән әчлек!

Хәйләсе

Көнозын ниндидер бер төрле әйбер әзерләгәнче, һәр көн саен, төрле рецептлар кулланып, 2–3 банка гына ясап куегыз. Рецептын язып, банкага ябыштырыгыз. Бу киңәшне тотсагыз, кышын аларның тәмен чагыштырып, иң ошаганнарын киләсе сезонда тагын да камилләштерә алачаксыз!

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ КЫЯР

Дания ГЫЙЛЬМИЕВА рецепты

Бер литрлы банка өчен: *700 г кыяр, 3–4 сарымсак теше, 15 чия, 1 аш кашыгы кызыл карлыган, 2 укроп зонтигы, 5әр чия һәм карлыган яфрагы, 1 керән яфрагы, 2 чәй кашыгы тоз, 4 чәй кашыгы шикәр комы, 30 мл шәраб серкәсе.*

Кыярны салкын суга салып, төнгә калдырабыз. Чия һәм карлыганны юабыз.

Банканы парландырып, карлыган һәм чия яфраклары, укроп, керән, сарымсак салабыз. Кыяр һәм җиләкләрне тутырабыз. Кайнап торган су салып, капкач белән каплыйбыз. 5 минут тотабыз. Суын агызып, кайнатып чыгарабыз һәм тагын банкага тутырып, 5 минут тотабыз.

Янә суын агызып алабыз. Шикәр комы, тоз, аш серкәсе өстәп, кайнатып чыгарабыз. Тозлыкны банкага тутырып, капкач белән борып ябабыз. Банканы астын өскә әйләндереп, суынганчы, җылы япма белән каплап тотабыз.

Аш-су

Җәйге бутерброд

Тостерда бер телем икмәкне киптереп алабыз да шуңа эретелгән сыр сылыйбыз. Кыярны озынча итеп юка гына кисеп, өстенә куябыз. Ахырдан көнҗет яки көнбагыш орлыклары сибәбез. Бакчада кыярлар өлгергәч, иртәнге ашка бик кулай ризык әзерләү ысулы!

Кирәге чыгар

СВИТЕРНЫ ҮЗ ХӘЛЕНӘ КАЙТАРУ

Йоннан эшләнгән кием юганнан соң утырса, аны чәч кондиционеры ярдәмендә сузарга мөмкин.

Элекке үлчәменә кире кайтару өчен свитерны салкын су белән чайкарга кирәк. Шуннан соң ләгәндәге суны алыштырып, чәч кондиционеры өстәргә дә киемне шунда салып куярга. Свитерны кимендә ярты сәгать шул суда тотарга. Шушы вакыт эчендә кыйрыйларыннан бераз сузгаларга. Соңыннан тагын бер кат чайкап, өстәлгә җәеп киптерергә.

Киңәш

АП-АК БУЛАЧАК!

Саргайган ак киемне горчица порошогы ярдәмендә элекке хәленә кайтарырга була. Бер-ике аш кашыгы порошокны ләгәндәге кайнар суга салып эретәбез. Ак әйберләрне шунда салып, берничә сәгать тотабыз. Соңыннан гадәттәгечә юабыз.

Беләсезме?

Тизрәк өлгертү

Теплицадагы кыярларны тизрәк өлгертү өчен һавасындагы углекислый газ микъдарын арттырырга кирәк. Моның өчен савытлардагы суга сыер тизәген салып, аны әледән-әле болгатып торалар.

Аю чикерткәдән котылу

Бу «җанвар»ны юк итүнең бик нәтиҗәле бер ысулы – көздән бакчага горчица чәчеп калдыру. Ул туфракны фосфор һәм күкерт белән баету гына түгел, бәлки әле корткычларның да эзләрен суытачак.

Викторияне мулчалау

Бакча җиләге төпләрен ылыс чүбе белән мулчалау әйбәт. Җиләге тәмлерәк булачак, корткычлар һәм авырулар да борчымаячак.

ТЫНЫЧЛЫК ЙОРТЫ

Мәчет – мөселманнар өчен иң изге урыннарның берсе. Безнең өчен көч һәм рух чыганагы да ул. Һәр йортның үз кагыйдәләре булган кебек, мәчетнең дә үз таләпләре бар. Анда нәрсә эшләргә ярый да нәрсәдән тыелып тору хәерле?

«Иман нуры» мәчетенең икенче имам-хатыйбы Әхмәт хәзрәт ФӘЙЗУЛЛИН мәчеткә бәйле сорауларыбызга җавап бирде.

? Халыкта: «Мәчет – бик тынгысыз урын. Анда ялгыш йокыга китсәң, кеше саташа, бастырыла», – дигән фикер яшь. Бу чынлап та шулаймы?

– Бу халык арасында йөри торган ырым-шырым гына. Мәчет ул – зикер, гыйбадәт кылына торган урын. Ә Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә Әр-Рәгъд сүрәсенең 28 нче аятендә: «Күңелләр Аллаһны зикер итү белән тынычланмыймы?» – ди.

? Бүген күп кенә авылларда мәчет ишегә бикле. Аны кирәк вакытта гына ачалар. Ягъни анда теләсә кайсы вакытта кереп, дога кыла алмыйсың. Динебез бу уңайдан ни ди?

– Намаз укылган вакыттан тыш, мәчетне ябу бары тик аның мөлкәтенә зарар килү куркынычы булганда гына рөхсәт ителә. Башка очракларда мәчетне бикләү мәкруһ гамәлләрдән санала.

? Мәчет иденәнә оекбашсыз, яланаяк басу гөнаһмы?

– Мәчеткә оекбашсыз керү гөнаһ түгел, ләкин бу чисталык ягыннан таләп ителә. Чөнки мөселманнар шул иденгә ятып сәҗдә кыла, ә кешенең аягында төрле авырулар булырга мөмкин, шуңа күрә оекбаш кию сорала.

? Хатын-кызга күрем вакытында мәчеткә керергә ярыймы?

– Хатын-кызга күрем вакытында мәчеткә керү тыелган. Әмма мәчет ишегалдына керергә ярый. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Мин күремле һәм җөнебле (госел алырга мәҗбүр булган) кешегә мәчеткә керүне рөхсәт итмим», – дигән.

? Бүген күпләр никах мәҗлесләрен мәчеттә генә уздыра. Иман йортында мондый мәҗлес уздыру дөресме? Анда җыр, музыка яңгыратырга рөхсәт ителәме?

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Мондый мәҗлесләр, гадәттә, мәчетнең үзендә түгел, ә аерым яисә мәчеткә тоташтырылган башка бинада – махсус мәҗлесләр залларында үткәрелә. Мәчетнең үзендә, әлбәттә, шундый мәҗлесләрне үткәрү рөхсәт ителмәгән, чөнки кешеләр анда гыйбадәт кыла. Гомумән, мондый җырлы-биюле мәҗлесләрне үткәрүнең үз шартлары үтәлергә тиеш. Бигрәк тә бер-берсенә чит булган ирләр һәм хатын-кызлар бергә катнашып утырырга, җырларга, биергә тиеш түгел.

? Укучыбыздан бер сорау килде. «Авылыбызда мәчетне төзекләндерәбез. Иденнәрен алыштырдык. Түбә калайларын яңарттык. Аннан чыккан иске такта, калайларны ни эшләтергә икән?» Укучыбызга ни дип җавап бирер идегез?

– Иске мәчеттән чыккан калай белән такталарны файдага куллансагыз, хәерлерәк булыр. Бәлки, аларны мохтаҗ кешегә бирерсез дә ул үз йортын төзекләндерер. Ләкин әлеге материалларны абзар, бәдрәф шикелле урыннарда куллану хәерле булмас. Бирергә кеше табылмаса, мәчеттән чыккан иске агач, такталардан утын әзерләп яндырырга да мөмкин.

? Элек мәчет булган урынга йорт салырга ярыймы?

– Мәчет өчен билгеләнгән җир Кыямәткә кадәр мәчет булып кала. Җир мәчет булып саналсын өчен, бина төзеп кую шарт булып тормый. Бу җирне үз файдаңа кулланып булмый, ул фәкать гыйбадәт урыны булырга тиеш.

Белеп тор!

Мәчет әдәбе

1 Мәчеткә керергә ниятләнгән кеше бәдәни (физик) яктан, ягъни җөнебтән (госелсез халәттән) чиста булырга тиеш. Шуңа күрә госел коенмый торып мәчеткә керү тыела. Бәйрәм һәм җеназа намазлары өчен ачык һавада билгеләнгән махсус урыннар, шулай ук мәчет ишегаллары мәчет статусына ия түгел, шуңа күрә госел алмаган кешенең анда керергә хакы бар.

2 Мәчеткә тәһарәтсез керү рөхсәт ителсә дә, бу гамәл хупланмый.

3 Хәнәфи хокук мәктәбе галимнәре фикеренчә, мөселман булмаганнар теләсә нинди мәчеткә керә ала, чөнки мәчеткә кергәннән соң аларның, ислам дине бөеклеген аңлап, аны кабул итүләре ихтимал.

4 Мәчеткә тәртип кагыйдәләрен үти алмаган балалар һәм акылы зәгыйфь кешеләрнең керүе хәерле түгел. «Тәмйиз» яшенә (бу яшьтә баланың акылы камилләшә һәм ул яхшыны яманнан аера ала) җиткән балаларны мәчеткә алып килү, җәмәгать белән бергә намаз кылырга өйрәтү һәм мәчеттә Коръән укыту хуплана.

5 Мәчеткә кергән мөселман «Тәхийәтел – мәсҗид» (мәчеткә сәлам бирү) исемле намазның ике рәкәгатен укыса, сөннәтне үтәгән булыр.

6 Кеше мәчеттә булган вакытта азан ишетсә, җитди сәбәпсез мәчеттән намаз укымыйча чыгып китәргә тиеш түгел. Мәчеттән азан ишеткәч чыгып китү гөнаһлы гамәлләрдән санала.

7 Мәчетләрдә тынлык булырга тиеш. Мөселманнарның тынычлыгын, аларның рухи халәтләрен бозарлык нинди дә булса хәрәкәттән сакланырга кирәк. Башка кешеләрне этеп-төртеп алга чыгарга маташу яки намаз укучының алдыннан үтү хупланмый.

8 Расүлуллаһ кушуы буенча, сарымсак кебек тәмсез ис килгән ризыкларны яңа гына ашаган кешеләр мәчеткә килергә тиеш түгел.

9 Мәчеттә әкрен генә, башкаларны борчымыйча сөйләшү рөхсәт ителә. Шуның белән берррәттән мәчеткә фәкать сөйләшү өчен генә килү мәкруһ санала.

10 Мәчеттә ашау һәм йоклау мәкруһ санала. Бу гамәлләр бары тик сәяхәт яки мәчеткә кунак булып килгәндә генә рөхсәт ителә.

Йөгез, бер дога!

МӘЧЕТКӘ КЕРГӘНДӘ УКЫЛА

«Салават» әйткәннән («Бисмиллаһи вәссәләту вәссәламу галә рәсүлиллаһ») соң, түбәндәге дога укыла: «Аллаһумма фтах ли әбваба рахмәтик».

Мәгънәсе: «Йә Аллаһ! Миңа Рәхмәтеңнең ишекләрен ач».

МӘЧЕТТӘН ЧЫККАНДА УКЫЛА

Яңадан «салават» әйткәннән («Бисмиллаһи вәссәләту вәссәламу галә рәсүлиллаһ») соң, түбәндәге дога укыла: «Аллаһумма инни әсъәлүкә минфадлик».

Мәгънәсе: «Йә Аллаһ! Дөреслектә, мин Синнән олуг фәзыйләт (өстенлек) һәм Рәхмәтеңне сорыйм».

** Мәчеткә уң аяктан керү, сул аяктан чыгу сөннәт санала.*

Хәдис



Дөньяда комсыз булма, сине Аллаһ яратыр, кешеләр кулында булган нәрсәләргә кызыкма, сине халык яратыр.

Гыйбрәтле кыйсса

Үзеңә кайта

– Күпкатлы йортларның ишегалларындагы агачлар һәм үләнгә су сибү – идарәче оешма эше, юл һәм тротуар читендәге агач-куаклар өчен район хакимияте җаваплы, ә парк һәм скверларны өлешчә Парк һәм скверлар дирекциясе һәм Казан башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты карап тора. Муниципаль килешү нигезендә агачларга су сибүче подрядчы оешмалар көчәйтелгән режимда эшли. Әмма эсселек сәбәпле барлык агачларны да карап бетерә алмыйлар. Казан буенча су сибүнең махсус графигы гамәлдә. Тәүлек әйләнәсе 40 машина эшли. Ун яшькә кадәрге агачларны карап торалар. Гамәлдәге нормативлар нигезендә, бер агачка 50 литр су сибелә, машина бер килүдә 160 агачка су сибә. Ә аннары аңа яңадан су тутырырга кирәк. Ул әйләнеп килгәнче, «бөке»ләрдә утырганчы, билгеле ки, вакыт уза. Моны да истә тотсыннар иде. Кайбер агачлар компенсация рәвешендә, ягъни киселгәннәре урынына утыртыла. Андый үсентеләрне район хакимияте балансына тапшырганчы, өч ел дәвамында утырткан оешма карап торырга тиеш.

Нинди штраф?

Казанга бик сирәк барабыз. Шуңа күрә андагы тәртипләрне дә бик белеп бетермим. Җәй башында Казанга хастаханәгә барган идек. Машинаны дөрес урынга куймаган өчен штраф килгән. Баксаң, муниципаль машина кую урыны өчен түләмәгәнмен икән. Бу штрафны ничек тикшереп була?

Дамир ГАФИЯТУЛЛИН.
Нурлат районы

Казан мэриясенең матбугат хезмәте:
– Казан шәһәре административ комиссиясе чыгарган карарларның күчермәләре автомобиль хуҗасының яшәү урыны буенча почта аша җибәрелә. Штрафлар (аларның көне, вакыты, урыны, фотосурәтләр һәм ТР Административ хокук бозулар турындагы кодекс маддәләре) турында мәгълүматны Казан мэриясенең интернет-порталындагы (kzn.ru) шәхси кабинет аша да белешергә мөмкин. Шунысын да искәртик: хокук бозуны дәлилләүче фотосурәтләр, бу урында автомат режимда эшләүче махсус техник чаралар куелган очракта, муниципаль машина кую урыны өчен түләмәгән яки автомобильне яшел зонага куйган очракта гына тәкъдим ителә. Штрафлар, аларны ничек тикшерергә икәнен рәсми сайтта «Штрафларны тикшерергә» төймәсенә басып та карарга мөмкин. Узган ел автомобиль йөртүчеләргә муниципаль машина кую урыны өчен түләмәгәнгә 387 мең сумлык штраф салынган.

Эльвира ВӘЛИЕВА әзерләде

«УРМАН КЫЗЫ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Хәтеремдә, кечкенә чакта урманда печән дә чабалар иде. Урманчыга махсус өлеш калдыралар. Кая ул, урманчы рөхсәтеннән башка биредә җиләк тә җыярга ярамый иде. Шуңа күрә урман чиста торган. Чикләвеге дә, җиләге дә, утыны да, себеркесе дә булган. Ә хәзер урман пычрак. Чөнки урманчылар тикшерми, гомумән, юк алар авылда. Мин үзем дә урманда еш йөрергә ярата идем. Догаларымны укып, ялгыз урманга кереп китәм дә, җырлый-җырлый җыеп, күтәренеп чыга идем урманнан рәхмәт әйтеп. Барысы да бар иде. Ни кызганыч, хәзер алай түгел. Бик матур язма. Бөтен кеше дә болай йөри алмый.

Галина ЕРЕМЕЕВА

«ТӨНГЕ АВЫЛДА... ТӨЛКЕ ЙӨРИ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Төлкеләрне авыл эчендә атарга ярамый икән. Таптылар җавап. Әйе, төлкеләрне стройга тезеп урман буена алып барырга кирәктер шул. Актаныш районының Киров авылы халкы тавык асрарга да курка хәзер. Чөнки төлкеләр күп. Әле күренмичә торганнар иде. Менә тагын күренә башлаганнар.

Зәмзәмия РӘХМӘТУЛЛИНА

2013нең ОНЫТЫЛМАС ИЮЛЕ

МОННАН 10 ЕЛ ЭЛЕК КАЗАНДА ҖӘЙГЕ УНИВЕРСИАДА ЯРЫШЛАРЫ УЗДЫ

tatarstan.ru

Татарстан башкаласын дөньяга таныткан вакыйга нибары 12 көн дәвам итте. Аның каравы шәһәрне дә, кешеләрне дә үзгәртте ул.

Меңьеллыкка әзерләнгәндә яңа сулыш өрелгән Казанда бәйрәмнән соң тагын бер зур проекта алынулары гаҗәп түгел. Эше дә, ашы да була андый чараларның. Моңарчы бары белгечләр генә белгән Универсиада уздыру фикерен Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә ул вакыттагы спорт министры Марат Бариев җиткерә. Тәкъдимне исә 2005 елда Төркиянең Измир каласында узган Җәйге Уеннар чемпионы, җиңел атлет Елена Мигунова авызыннан әйттерәләр. Инде бер елдан Казан, 2011дә Универсиада уздыру хокукын сорап, Халыкара студентлар спорты федерациясенә (ФИСУ) мөрәҗәгать итә.

Ул вакытта бу чараның нинди буласын беркем дә күз алдына китерә алмады. Башта Мәскәүне ышандырырга кирәк иде. Каршы чыгучылар булды. Илдә 1980 елгы Олимпиададан бирле мондый зур спорт чарасының узганы юк, яңа гына Меңьеллыкны бәйрәм иткән Татарстан нинди «Сабан туе» уздырырга җыена, янәсе. Әле, җитмәсә, Сочи Олимпиадасына әзерләнәсе бар. Әмма Шәймиев командасы ышандыра алды. ФИСУда да кочак җәеп каршы алмадылар: 2011 елгы Универсиаданы Кытайдагы Шеньжень каласына бирделәр. Казанны Казахстан белән бутаган вакытлар әле бу. Соңыннан бу карарның безнең файдага булганын аңладык. 4 ел эчендә бу кадәр эш башкарып өлгерү мөмкин булмас иде. Кытайда ниләр булып ятканын күреп кайткан түрәләр үзләре дә таныды моны. 2013 елгы Универсиаданы уздыру хокукын яулаганда инде Мәскәүдәге министрлыкларга һәм ФИСУга сукмаклар такырлана төшкән иде.

Моннан 10–15 ел элек: «Нәрсә ул Универсиада?» – дип сорасаң, Казанда биш кешенең дүртесе: «Төзелеш», – дип җавап бирер иде. Хәтта куркып калучылар да булды. Берничә ел эчендә шәһәрдә дистәләгән спорт корылмасы калкып чыкты. Үзе бер кечкенә кала булырлык Универсиада авылы төзелде. Аэропорт, метро һәм яңа вокзал ачтылар. Яңа юллар исә Татарстан башкаласын берничә елга «бөке»ләрдән коткарды. Танымаслык булып үзгәргән башкала илдәге төп туризм үзәкләреннән берсенә әверелде. Ә иң мөһиме – бөтен дөньядан кунаклар кабул иткән Казанда кешеләр үзгәрде. Кеше белән аралашырга, яхшырак яшәргә, үз шәһәрен яратырга, горурланырга өйрәнде. Нибары 12 көн дәвам иткән вакыйганың төп нәтиҗәсе бу.

ҖӘЙГЕ УЕННАРДА 160 ИЛДӘН 11778 КЕШЕ КАТНАШТЫ

Ярышларда **2430** хөкемдар һәм **1500** журналист эшләде, **800** мең кеше тамаша кылды. Татарстан башкаласына **150** меңнән артык кунак җыелды. Универсиадага килгән халыкка Россия төбәкләре һәм **37** чит илдән җыелган **19970** волонтер хезмәт күрсәтте.

31 СПОРТ КОРЫЛМАСЫ КАЛКЫП ЧЫКТЫ

Иң зурлары – **45** мең кешелек «Казан Арена» стадионы, Спортның судагы төрләре сарае, «Ак барс» көрәш сарае, Теннис академиясе, Гимнастика үзәге, «Санкт-Петербург» волейбол үзәге.

530 КОРЫЛМА ТӨЗЕЛДЕ ҺӘМ ТӨЗЕКЛӘНДЕРЕЛДЕ

Хәзер студентлар шәһәрчегенә әверелгән Универсиада авылы салынды, Казан халыкара аэропорты яңартылды, аэроэкспресс линиясе, **3** метро станциясе төзелде, «Казан-2» вокзалы ачылды, яңа трамвай линиясе эшли башлады, **11** транспорт чишелеше пәйда булды. Универсиадага әзерлек вакытында төзүчеләр **657** мең кубометр бетон салды, **2** миллион кубометр ком ташыды, **1,3** миллион тонна асфальт түшәде.

СПОРТЧЫЛАР 27 СПОРТ ТӨРЕНДӘ ЯРЫШТЫ

Россия спортчылары **155** алтын, **75** көмеш һәм **62** бронза – барлыгы **292** медаль яулады. Командалар беренчелегендә Кытай – икенче, Япония өченче булды. Маргарита Мамун (нәфис гимнастика), Владимир Морозов (йөзү), Виктория Андреева (йөзү), Юлия Ефимова (йөзү) **4**әр алтын медаль яуладылар. Ярышларда Универсиаданың **67** рекорды яңарды. Татарстан спортчылары Универсиадада барлыгы **40** медаль отты.

Үзебезнең көрәш

Казан Универсиадасы ярышлары спортның 27 төре буенча узды. Шуның 13е мәҗбүри булып саналса, калганнарын кабул итүче як тәкъдим итте. 2011 елда Шэньчжэньдәге Җәйге Уеннарда 26 төрдә ярышсалар, Казанда тагын берне өстәделәр. Татарстан башкаласында көрәш ярышлары да булды һәм ул безнең егетләргә Универсиада чемпионы исемен яулау мөмкинлеге бирде.

Дөрес, көрәшне ярышлар программасына кертү җиңел бирелмәде, бу мәсьәләдә төрле бәхәсләр булды. Хәтта ки аны нинди исем белән уздыру турында да озак уйландылар. Ахыр чиктә Универсиадада билбаулы көрәш буенча классик һәм иркеле төрдә бәйгеләр узды. Беренчесендә татар көрәшендә танылу алган егетләр бил алышты. Үз авырлыкларында Биектаудан Нәфис Миңнебаев, Теләчедән Илдар Гыйниятуллин, Сарман районында туып-үскән Илнар Галиев, Казаннан Илнур Мортазин, Чаллыдан Ринат Әхмәтшин һәм Ульяннан Сергей Павлик җиңүче булып танылды. Турнирның баш батырын да ачыкладылар. Бу исемне, аңлашыла инде, татар көрәшендә иң дәү гәүдәле егетләрдән саналган Сергей Павлик яулады.

Хәзерге вакытта бу егетләрдән Сергей Павлик кына көрәшеп йөри. Калганнары келәмгә чыкмаса да, көрәштән ерак китмәделәр. Чемпион егетләрдән кайберләренең хәлен белештек.

Нәфис МИҢНЕБАЕВ,
Универсиадада 60 килолы егетләр арасында җиңүче, хәзерге вакытта Татарстанның спорт көрәше федерациясендә башкарма директор:

– Иң җиңел категория булгач, чемпион исемен беренче булып яулау бәхете миңа насыйп булды. Универсиада – халыкара югарылыктагы вакыйга, шуңа күрә ул татар көрәшен дөньякүләм дәрәҗәгә күтәрергә ярдәм итте. Безгә исә беренчеләр сафында булу бәхете тәтеде. Шуннан соң ел саен дөнья чемпионатлары уза башлады, егетләр зур җиңүләргә иреште. Ничек көрәшкәнемне, тамашачының безнең өчен ничек җан атканын әле дә хәтерлим. Кайбер сәбәпләр аркасында дөнья чемпионатына барып җитмәсәм дә, күп тапкыр Муса Җәлил турнирында, Татарстан һәм Россия чемпионатларында җиңү яуларга туры килде. Әлбәттә, бу ярышларда көндәшлек бик зур, җиңү бик авыр бирелә. Яшермим, Универсиадада уңышка ирешү ул яктан җиңелрәк булды. Әмма әһәмияте зуррак. Шуңа күрә искә алабыз да бит инде.

Илдар ГЫЙНИЯТУЛЛИН,
Универсиадада 70 килолы егетләр арасында җиңүче, хәзерге вакытта Теләчедә спорт мәктәбе директоры:

– Универсиадага көрәшне керткәч, әлбәттә, сөендем. Әмма бераз курку да булды: бөтен егетләр җиңеп, мин оттырсам, оятын кая куярмын?! Җиңсәң, герой буласың, ә үзебезнең көрәштә оттырсаң, кеше көлкесенә калырга мөмкинсең. Иң беренче фикер әнә шундый булды. Шөкер, максатыма ирештем, барлык алышларымны да хәтерлим, бик тә горурланганым истә. Зур вакыйга булды ул. Әмма бу җиңү минем өчен иң зурысы дисәм, арттыру булыр. Чөнки аңа кадәр дә уңышлар аз булмады, спорт остасы исемен алдым. Әмма Универсиада мине үземә карата таләпчән булырга өйрәтте, әзерлек бик яхшы иде. Сайлап алу ярышлары алдыннан 8 кило авырлыктан котылырга, ә төп ярышка чыгу өчен 12 килога ябыгырга туры килде. Универсиадага ныклап әзерләнү аркасында тагын берничә ел дәвамында келәмдә яхшы нәтиҗәләргә ирештем әле мин.

Ринат ӘХМӘТШИН,
Универсиадада 100 килолы егетләр арасында җиңүче, хәзерге вакытта Чаллыда «Виктория» спорт мәктәбе директоры:

– Артка борылып карыйсың да, әле кичә генә булган кебек. Мин Универсиада тарихына кереп калдым, ә Универсиада әле дә минем белән. Барыбыз өчен дә зур бәйрәм булды ул. Ярыш кына түгел, зур тәҗрибә дә, әзерлек тә, җаваплылык та, сынау да, омтылган максатыңа ирешү юлы да булды. Шөкер, шуңа ирешә алдык. Кабат мондый мөмкинлек булмаячагын аңлый идем. Шуңа күрә республика җитәкчелегенә көрәшне Универсиада программасына керткән өчен рәхмәт. Ник дигәндә, бу вакыйга көрәшчеләргә шатлык һәм өмет бүләк итте. Шундый бәхет татырга насыйп булганга әле дә сөенәм. Әйе, баш батыр исеме өчен бил алышканда агаеымны авырттырдым һәм хастаханәгә ятарга туры килде. Әмма тамчы да үкенмим, тормышта була торган хәл. Универсиада миңа онытылмас хатирәләр калдырды. Хәзер инде келәмгә чыкмасам да, көрәштән китмәдем. Спорт мәктәбен җитәкли башлагач, иң беренче эш итеп көрәш бүлеге ачтым.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

МӘРЬЯМ ГАТИНА:

«ӘНИЛӘРЕ БУЛЫРГА ТЫРЫШТЫМ»

Апас районының Каратун бистәсендә яшәүче 76 яшьлек Мәрьям Гатина бар кешегә дә үзенеке төсле картлык тели. Балалары аны кадер-хөрмәттә яшәтә. Кайчандыр әнисез калган өч балалы йортка килеп кергән Мәрьям апа хәзер шулардан игелек күрә.

– Кызыл Тау авылында туганмын. Әтием бик оста гармунчы, тирә-якка даны таралган сәгать төзәтү остасы иде. Әни дә, әби дә кул эшләренә хирыс булулары белән аерылып тордылар. Мин дә эшкә өйрәнеп үстем. 7 класста укыганда тегү машинасы алып бирделәр. Әни аны 800 йомырка сатып алды. Машина алып кайтуга күрше апа күлмәк тегүемне сорап керде. Ничек эшләгәнмендер, әмма булдырдым, – дип искә ала Мәрьям апа. – Әле хәзер дә бер төн эчендә бер күлмәк тектем бар. Әгәр кирәк икән, төне буе да утырып эшлим, көннәр буе да утырырга иренмим. Оныгыма кәнфит кәгазьләреннән дә күлмәк тегеп бирдем. Бер күлмәккә барлыгы 5 меңләп кәнфит тышы китте.

Мәрьям апа баянда уйнарга да өйрәнгән. Бу осталыгы Урта Балтай клубына китерә дә инде аны. Шул чакта авылларында яшәүче бер гаиләгә хәсрәт килә. Апаска юл тоткан ир белән хатын юл фаҗигасенә очрый. Аларны утырткан машина йөртүче белән гаилә башлыгы исән кала. Ә менә 43 яшьлек Нурия, өч баласын ятим калдырып, вафат була.

– Мин ул вакытта кияүдән кайткан идем. Ирем белән озак яши алмадык, 9 ай торгач, аерылыштык. Балабыз булмады. Нурия апаның ире Хәйдәр өч бала белән тол калгач, мине аңа димләделәр. Яшь арабыз 13 ел иде. Әти белән әни каршы килмәде. Аеруча: «Балам, ул балаларга да әни кирәк бит. Кем дә булса, аларны үстерергә тиеш. Каршы килмә», – дип үгетләде. Ул вакытта мин Хәдичә исемле әбигә фатирга кергән идем. Үзем дә кияүгә чыгарга каршы түгел. Тик Хәдичә әби мине, бирмим, ди. Мине дә, чыкма, дип үгетли, чит балаларга әни була алмассың, ашыкма, ди. Әти белән әни кушкач, мин ничек каршы килим? Үзем дә ул балаларны уйладым, – дип искә ала Мәрьям апа ул көннәрне.

Хәдичә әби кызны өйдән чыгармый. Мәрьям апаларның киленнәре төнлә килеп, әнигә нидер булды, дип алдалап кына алып чыга. Бу төнне Мәрьям апа кияүгә чыга.

Автор фотосы

– Өстемдә кофта белән итәк. Бездә кыз кеше кияүгә тоташ күлмәк киеп чыгарга тиеш дигән ырым бар иде. Хәдичә әби йортына кире кереп булмый, өстемдәге киемем өчен дә борчылам. Аллага тапшырып, Хәйдәрләр өенә килеп кердем. Ул чакта күп кеше минем бу адымымны яратып та бетермәде. Янәсе, әзер тормышка килеп керде, диделәр. Авыр сүзләр булса да, үземнең күңелне белгәнгә, сабыр иттем. Иң мөһиме – гаиләдәге мөнәсәбәт иде, – ди Мәрьям апа. – Мин килгәндә иң олы бала Рамилгә 18 тулып киткән чак. Ул укырга керә алмыйча, бер ел безнең белән яшәде. Рамиләгә – 13 яшь. Биергә яратты ул. Әниләре дә оста биегән. Рамилә янымнан китмәде дә. Гөлчәчәккә 4 кенә яшь иде әле. Кечкенәләр «әни» дип үсте. Рамил әйтә алмады. Буй җиткән егет бит инде. Үзем дә «әни» дип әйтмәвенә әллә ни игътибар бирмәдем.

Соңрак улыннан да әни дигән җылы сүзне ишетә ул...

– Хәйдәр белән кушылгач, мин бар җылымны шушы балаларга бирдем. Алар әниләре юклыкны сизмәсен өчен тырыштым. Күңелемдә бер дә начарлык булмады. Гомер буе тегү теккәч, балаларымны гел матур киендереп йөрттем. Кичтән чалбар кисәләр, икенче көнгә ул күлмәккә дә әйләнә иде. Дүртенчегә уртак балабыз Райләбез туды, – ди Мәрьям апа. – Хәйдәрем бик әйбәт булды. Аның белән рәхәт яшәдек. Көнләшеп йөрәккә тимәде. Кая барасым килсә, шунда җибәрде. Бер авыр сүз әйтмәде. Рәхмәтле була белде. Мәхәббәтнең ни икәнен әйтә алмыйм. Әмма без аннан да зуррак хис белән яшәдек. Гаиләбездә дә, икебезнең арада да хөрмәт булды. Минем 55 яшемне үткәрдек тә кунакларны көзгә көмеш туебызга чакырдык. Тик бәйрәм итү насыйп булмады. Хәйдәрем 68 яшендә йөрәк белән китеп барды.

Бу хәсрәтне балалары белән бергә күтәрә Мәрьям апа. Төп йортның җылысын саклап озак яши әле ул. Оныкларын да үстерешә. Соңгы елларда аны кызы Райлә үзе янына чакырган. Хәзер бар туганнар шунда җыелыша икән. Мәрьям апа бик бәхетле. Әле бер баласы кунакка алып китә икән, әле икенчесе.

Мәрьям апа турында язма әзерләгәндә, кызлары белән сөйләшергә туры килде. Алар әниләренә бик рәхмәтле. «Иң авыр чакта күңелебезгә ачкыч тапты. Кеше газиз баласыннан баш тартканда, әни безне үз канаты астына алды. Мине дөньяга китергән әниемне дә хәтерлим. Ул үлгәндә миңа 13 яшь иде. Мәрьям әниебез кечкенә сеңлебез тугач та, барыбызны тигез күрде», – ди Ульянда яшәүче олы кызы Рамилә. «Әни безгә ятимлек ачысын сиздермәде. Бик рәхәт яшәтте. Без аңа гомеребез буена бурычлы. Ничек инде якын итмисең, әни бит ул!» – ди кече кызы Гөлчәчәк.

Мәрьям апа исә кайчандыр әти-әнисен тыңлап кияүгә чыкканына сөенә. Мин әнинең әнисенең язмышын кабатладым, ди ул.

– Әбием дә дүрт балалы тол иргә кияүгә чыккан. Уртак бер балалары булган. Язмышлар кабатлана икән, – ди Мәрьям апа. – Кияүгә килгәндә, мин аны-моны уйлап тормаган идем. Ә хәзер инде нинди зур адымга баруымны аңладым. Балаларыма кыен чакта терәк булдым, алар исә хәзер мине рәхәт яшәтә. Игелекләрен күрәм. Күзләр тимәсен. Бик дөрес тәрбия алган балаларыма рәхмәтлемен. Гомерем бушка үтмәгән. Чит кешеләр килеп, дүрт балам хакында да җылы сүзләр әйтә. Бәхет бит инде бу!

НУРЛЫ НУРҖИҺАН

Безнең кодагый кебек кеше юк! Сабада яшәүче Нурҗиһан Харисова турында редакциягә шалтыратып шулай дип сөйләделәр. Күпме хәсрәт күрсә дә, сабырлыгын җуймаган, бик күпләргә үрнәк булган ул. Нурҗиһан апаның хәлен белергә дип шалтыраткач та, аны бик озак өйдә туры китерә алмадык.

– Җәй көне мине өйдә тотып булмый шул, – ди бер ай элек 80 яшен тутырган Нурҗиһан апа. – Рәхәтләнеп эшләп йөрим. Эш яратам. Бакчада яшелчә, җиләк-җимешнең өлгергән чагы. Киленнәремә шуларны җыеп бирәм. Кош-корт белән мәш киләм.

39 ел буе Сабаның икмәк заводында эшли ул. Хезмәтенә күрә хөрмәтен дә күрә. Мактаулы исемнәр дә ала, рәхмәт хатлары да җитәрлек.

– Авыр эш булса да, шөкер, әле дә аякта йөрим. Ул чакта арыла иде инде. Ә бит тормыш итәргә кирәк. Ирем дә гади эшче булды. Эретеп ябыштыручы иде ул. Эш кешене бетерми, хәсрәт бетерә икән, – ди Нурҗиһан апа.

2015 елда кызлары авырып китә аларның. Ничек кенә өметләнсәләр дә, аякка баса алмый Гүзәлия, 47 яшендә гүр иясе була. Нурҗиһан апаның йөрәгенең бер читен өзеп алалармыни?!

– Авыр чакта төп терәгем улым белән киленем булды. Туган-тумачалар, кода-кодачалар гел хәлемне белешеп торды. Кеше белән сөйләшеп, хәсрәтемне эчкә йоттым. Тик борчулар моның белән генә бетмәгән икән. Кызым артыннан гомер иткән ирем Рәис тә китеп барды, – ди Нурҗиһан апа.

Тормыш үз көенә тәгәри. Төп йортта яшәүче улы Мөдәриснең балалары буй җитә. Уллары Рәмис өйләнәм дип кайта. Шулай итеп киленнәре Нәзилә берьюлы ике каенана янына килеп төпләнә.

– Кызганыч, улым да кыска гомерле булды, өч ел элек 54 яшендә бакыйлыкка күчте. Онычымны читкә чыгарып җибәрәсе килмәде. Бар тормышыбыз шул балалар кулында бит. Без – ике әбине калдырып үзләре дә беркая да китмәде, – ди Нурҗиһан апа. – Олы киленем Дамирам белән 36 ел буена бик җайлы яшибез. Аның хакында сөйләп туя алмаслык. Бер-беребезгә авыр сүзләр әйтмәдек, хөрмәт итеп яшибез. Бәхетем булды да инде киленнәрдән. Кечесе дә олысына охшап килде. Әнисе белән икебезнең мөнәсәбәтләрне күреп тора бит ул. Әле кече киленем белән икәү бергә намаз да укыйбыз, ураза да тотабыз. «Әби» дип кенә тора. Безнең бәхеткә

Нурҗиһан Харисованың шәхси архивыннан

килгән бала булды инде ул. Шәфкать туташы булып эшли. Кайсы җирем авыртса да, аңа әйтәм. Даруларны алып кайтып тора. Аларның игелекле икәнлекләрен күрсәгез!

Дамира килене пешекче икән. Нурҗиһан апа аны мактый да мактый. Картлыгында кадер-хөрмәттә яшәткән киленнәренә рәхмәтле ул.

Күпме сөйләшеп, Нурҗиһан ападан зарланган сүз ишетмәдек. Хәтта югалтулар турында сөйләгәндә дә, язмышыма шулай язылгандыр инде, дип кенә куйды. Тормышны яратуы әллә каян күренеп тора аның. Җор күңелле, матур итеп көлеп тә куя. Гаиләдәге тынычлык, иминлек, татулыкның иң өлкән кешедән торганын белә ул. Әнә шуңа да һәр яктан үрнәк булып яши. Якыннары да безгә, Нурҗиһан апа янында рәхәт, диделәр.

– Иремнең сеңлесенең каенанасы ул. Безне бик якын итә. Дамирабыз белән тату яшәүне барыбызга да үрнәк. Безне дә үз итә. Начарлыкның ни икәнен белми ул. Әнә шуңа да Аллаһы Тәгалә аңа матур тормыш биргән дә, – ди кодачасы Зөлфирә апа. – Хәсрәтләрне дә күтәрә белде. Олы йөрәгенә бар нәрсә сыйган аның.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

РАЯЗ ФАСЫЙХОВ:
«ГОРУРЛЫК УЛ – БЕЗНЕҢ ТАНЫКЛЫК»

Ул, тырыш кешеләргә сокланам, дип әйтергә ярата. Ә үзе – татар эстрадасындагы иң тырыш җырчыларның берсе. Раяз ФАСЫЙХОВ һәрчак эзләнүдә: яңа алым, яңа образ дисеңме, яңа жанр, киноны хәтерләткән клипмы – болар барысы да берәмтекләп эшләнгән хезмәт нәтиҗәләре. Җырчы быел көз Казанда концерт куярга әзерләнә. Менә шулай озаклап, талымлап эшли ул әлеге эшен. Хәер, җырлары да озак туа аның. Сыйфатны беренче урынга куйгангадыр, мөгаен. Җырчы белән эстрада проблемалары, тормыш принциплары турында сөйләштек.

:: Синеңчә, без нинди вакытта яшибез, Раяз?
– Вазгыять, заман һәр минутның кадерле булуына төшендерде. Шуңа күрә мин һәр туган көнгә шатланып, шөкер итеп яшим. Тырышсаң, барысына да ирешеп була. Вакыт тизләнде, адәм баласына шуңа җайлашырга, өстәвенә һәр көннең үзгәрешләрен кабул итәргә өйрәнергә туры килә. Нишлисең, һәр заманның – үз авырлыгы.

:: Безнең заманда җырчыга, әйтик, Илһам Шакировлар заманы белән чагыштырганда, авырракмы, җиңелрәкме?
– Хәзерге заманда җырчы булып кына алга барып булмый. Шоу-бизнес законнарын аңларга, базар мөнәсәбәтләренә төшенергә һәм үзеңне һәрдаим камилләштерергә туры килә. Шулай иткәндә генә уңышка ирешеп була. Илһам абый заманында каты чикләүләр, худсоветлар булган, хәзер анысы юк. Бер яктан бу бик зур иркенлек бирә һәм теләге булган һәр кешегә, тавышы булмаса да, сәхнәгә юлны ача. Бик күңелле замана, бер караганда. Мөмкинлекләр күбрәк. Техник яктан да, радио-телевидениегә чыгу ягыннан да, концертлар оештыру җәһәтеннән дә. Чикләр һәм чикләүләр юкка чыкты. Әмма моның файдасы да, зыяны да булды.

:: Җырчылар хәзер, зал тутыру авыр, дип ешрак әйтә башлады. Моның сәбәбен нәрсәдә күрәсең?
– Зал тутыру синең ни дәрәҗәдә үҗәт, тырыш һәм шоубизда кайнавыңа бәйле. Грамоталы итеп эшләсәң, залны тутырып була. Бу – төрле ысуллар белән халык күңелен яулау дигән сүз. Халык күңелен яулап алдыңмы – зал тула. Ләкин үзеңне көчләп тагып булмый. Халык үзенә кирәген сайлап ала.

:: «Кыр казлары», «Эзләмә син кабат очрашулар» – хитка әйләнгән җырлар. Гомумән, һәр елны бер хит чыгарасың, дисәк тә, ялгыш булмас. Бүген «Горур булыйк», мәсәлән, гимн кебек яңгырый. Җыр ничек популяр булып китә? Беренче башкарганда ук бу җыр популяр булачак дигән ышаныч туа аламы?
– Бу җырларның өчесенең дә көй авторы – минем әти. Бәлки, алар халык нинди дер моңлы, романтик җырларга сусаган вакытта тугандыр, шуңа күтәреп алып хитка әйләндергәннәрдер. Чөнки җырны җырчы түгел, халык хитка әйләндерә. Бүген дә алар популярлыгын югалтмады. «Горур булыйк» җырын әти Фәнис Яруллин сүзләренә иҗат итте. Ул ничектер гимн кебек яңгырый. Милләтпәрвәр булырга, татар булуың белән горурланырга һәм шул горурлыкны киләсе буыннарга да тапшырырга кирәк. Әлбәттә, проблемалар бар, аларны барыбыз да беләбез. Әмма телне саклау җәһәтеннән дәүләтне, җитәкчеләрне генә гаепләргә дә минем ачуым чыга. Баланың нинди телдә сөйләшүенә, аның формалашуына син җаваплы. Кечкенәдән татарча сөйләшергә мәҗбүр итәргә кирәк. Өйдә татар мохите булса, урамда нинди телдә аралашуына карамастан, ул татар баласы булып формалашачак. Димәк, җаваплылык – әтиәнидә, әби-бабайда. Тәрбия дилбегәсен нык тотсалар, әле алда өмет бар.

> Без – горурланырлык милләт. Йөзек кашы булырдай әсәрләребез, горурланырлык язучыларыбыз, фәлсәфәчеләребез, композиторларыбыз, бөтен дөньяга танылган галимнәребез бар. Горур булыйк! Җырдагыча: «Милләт үлми, горурлыгы барда, горурлык ул – безнең таныклык», – дип күкрәк киереп яшик. Бу җыр хәзер бигрәк тә уйланырга мәҗбүр итә, каныңны кайнатып, уятып җибәрә, дип уйлыйм мин.

:: Бүген җырчы булам дип хыялланган яшьләргә нинди киңәш бирер идең?
– Җырлау сәләте булса, ул сәләтне үстерергә һәм, болай да җырлый белүем инде, дип тукталып калмаска кирәк. Үзенчәлекле тембрың бар икән, үстер, башка җырчыларны кабатлама. Һәр кешенең – үз юлы. Профессиональлеккә омтылырга, начарга игътибар итмәскә, вак белән вакланмаска кирәк. Популярлыкның төрле мәгънәсе бар бит аның. Вакытлыча популяр булырга була, гомерлеккә. Соңгысы – үзеңә матди яктан да, рухи яктан да кертем кертү, гел эшләү, тынгысызлык дигән сүз. Шуны оештыра алсаң, җырчы булып була. Бу яктан мин Зәйнәб Фәрхетдинованы, Филүс Каһировны, Гүзәл Уразованы хөрмәт итәм. Алар гел эзләнүдә.

:: Принципларыңа каршы килә торган эш-гамәл кылырга туры килгәне бармы?
– Мин – бик кире, үҗәт кеше. Шуңа күрә үземнең принципларга каршы килгәнем юк ...тыр. Каядыр матди койтышлык арасында сыгылып, сатылып йөргәнем юк. Әйтәм икән, шулай эшлим дип, кар яуса да, боз яуса да, аны эшлим. Принциплар аркасында кайвакыт авырга да туры килә. Ә иҗатта принцип булырга тиеш түгел, аны кысага кертергә ярамый. Тегесен дә җырлап карарга кирәк, бусын да, мөмкинлек бар икән, тәҗрибәгә дә алынырга була. Мәсәлән, Филүс Каһиров белән танышкач, минем дә классик әсәрләр башкарып карыйсым килде. Опера сәнгатенә дә кызыгып куйдым. Илһам Вәлиев, Әхмәт Агади, Рузил Гатин чыгышларына мөкиббән мин. Алар белән илһамланып, берәр ария җырлап карарга дигән хыял туды.

:: Ә нинди соң ул синең принциплар?
– Төп принцип – нинди генә вазгыятьтә дә кеше булып калу. Шоу-бизнес пычрак инде ул, диләр. Алай түгел. Күп нәрсә кешенең үзеннән тора. Бик тәртипле коллегалар да, икейөзлеләр дә бар, аларын да беләбез. Татар эстрадасында артистлар күп дисәләр дә, кечкенә бер авыл инде ул. Барысын да беләсең, һәр кешенең үзенчәлекләрен дә чамалыйсың. Әлбәттә, иҗат кешесе хыялый, хисле, шуңа күрә күп әйберләрне, ялгышларны кичерәсең дә. Бу җәһәттән сине дөресләп торучы дусларың булу сөенеч. Әтием китеп барса да, әти ягындагы яшендәге, кирәк булганда аркадан сөеп, кирәк булса, сүгеп торучы кешеләрем бар. Хатыным Люция дә бик акыллы. Минем иҗатта аның да өлеше бик зур.

:: Эстрадада төп проблеманы да әйтеп карыйк әле.
– Продюсерлар җитмәве, һәр җырчының үз-үзенә продюсер булырга тырышуы. Ул – бик катлаулы эш. Мин, мәсәлән, җырлап кына йөрер идем, продюсерлык мәсьәләләре белән башымны катырмас идем. Ул эшнең мәшәкатьләре очсыз-кырыйсыз бит. Анда реклама мәшәкатьләре дә, имиджмейкер мәсьәләләре дә, нәрсә генә юк – әле болары күзгә күренеп торганнары гына. «Барс-медиа» компаниясе ул яктан әйбәт кенә эшли һәм үсә иде. Ләкин алар оешып бетә алмады, кызганыч, таралыштылар. Менә шундый социаль мохит, лаборатория, үзәкләр кирәк. Анда талантлы яшьләр белән эшләрләр, бергәләп җыр сайларлар, аранжировка ясарлар, клип төшерерләр иде. Бу – бик зур эш. Хәзергә татар эстрадасында продюсерлар юк дисәк тә була. Артист үзе ура, үзе суга, үзе җилгәрә дигәндәй, бөтен эшне үзе башкарырга тырыша. Кемнеңдер килеп чыга бу, ә кемнеңдер юк. Нәтиҗәдә менә дигән талантлар югала. Икенче проблема – сыйфат мәсьәләсе. Бусы бигрәк тә радио-телевидениедәге чыгышларга кагыла. Безгә еш кына чит төбәкләрдә дә чыгыш ясарга туры килә, шунда: «Телевидениедә бөтен кешегә дә җырларга ярыймыни?» – дип сорап куялар. Чыннан да, безнекеләрне озак карап булмый, тизрәк башка каналга күчәсе килә. Рус каналларын алсак, анда ул дәрәҗәдә үк сыйфатсыз контент белән эшләмиләр. Бездә ничектер бу мәсьәләгә игътибар юк кебек. Акчасы булган «любой» кешегә җыр да яздыралар, клип та төшерәләр, күрсәтәләр дә. Таланты чамалы кешеләр күбрәк булу аркасында сәләтлеләр күләгәдә кала. Безнең араларны чистартырга вакыт дигән сүз инде бу. Сәләтлеләрне барлый торган иҗат үзәге булсын иде, дим шуңа да. Бәлки бардыр да ул, һәрхәлдә гамәлләре күренгәне юк.

:: Киләчәккә нинди планнарың бар?
– Күптән инде Казанда концерт куйган юк. Март аенда берничә җиргә чыгып кергәч, канатландым да башкалада үземнең концертны куясы килә башлады. Анда кызыклы тәҗрибәләр дә булыр, дуэтлар да.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Блиц сораштыру

– Җыр – синең өчен нәрсә?
– Ул – тормышның бер кыйпылчыгы, бер тарих. Минем өчен ул гади генә нәрсә түгел. Мин аны үз башымнан кичерәм, дулкынланам. Шуңа күрә һәр җырым озак туа. Җыр ул – сүз һәм көй авторлары, аранжировка ясаучы һәм җырлаучының уртак бер иҗаты. Ул кешедә роман укыгандагы кебек үк дулкынландыргыч тәэсир калдырырга тиеш.
– Шундый мөмкинлек булса, тормышыңда нәрсәне үзгәртер идең?
– Мин моңа җавап бирмәмдер... Үзгәртәсе килә икән, тотасың да үзгәртәсең инде аны.
– Холкыңны биш сүз белән тасвирлап бирә аласыңмы?
– Мин тугры дус, үҗәт, табигать баласы, оптимист, Аллага рәхмәтле.
– Бүген кәефеңә нинди җыр туры килә?
– Эльмира Җәлилова сүзләре, Фирзәр Мортазин көенә «Яшик әле» дигән җыр.
Яшик әле яшен булып, ут булып,
бу дөньяда гомердән дә
кадерлерәк берни юк.

АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА

ТУЗГАНАК КЕРФЕГЕ

(ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК)

Авылдашым
Гөлфәгыйдә апа Юлышевага
багышлыйм

Монда барысы да танымаслык булып үзгәргән иде: таулар чүккән, күлләр саеккан, чишмә кибеп корыган; кайчандыр җил уңаена түбәсен кыңгыр салып утырган өйләр урынында исә кияү көткән кәләштәй бизәнгән-ясанган ташпулатлар кукрая, җилкапка һәм читән койма дигәнне күптән оныткан ишегаллары чебен түгел, җил дә үтеп керә алмаслык калай, шул калай өстеннән чәчәкләп-чуклап беркетелгән тимер рәшәткә артына поскан. Шул ук вакытта монда берни дә үзгәрмәгән: кешеләр барысы да нәкъ элеккечә иде. Җанның олылыгына йә булмаса ваклыгына заманның бер катнашы да юк, ахрысы...

Авылның быелгы Сабан туе, ни хикмәттер, яңгырсыз узды. Тамаша карарга килүчеләрдән битәр, туңдырма, баллы су, уенчык-мазар сатучыларны сөендереп, көн буе кояш елмайды. Биш бәясенә артырып саткан товарларының кулдагы балык урынына шуып кына торуын күреп, сатучылар үзләре дә кояштан ким балкымады. Төтен исенә ыслана-ыслана чучка шашлыгы пешереп ятканнар, тикшерүчеләр күзеннән ничек тә яшереп аракы, сыра сатарга маташканнар: «Салкын булса, шәбрәк үтәр иде», – дип зарланышып алса да, көн кәефен үзгәртмәде.

Усай авылы Сабан туе ел саен бер үк урында – сылу каеннар белән уратылган, ак чәчәкле җир җиләге түшәлгән түгәрәк аланда үтә. Аланнан әллә ни ерак түгел, инде суы тәмам саегып, уч төбе кадәр генә калган Каз күле шәйләнә. Авыл үзе таулы урында урнашкан: озын-озын өч урамга тезелгән йортлар барысы да шактый текә бер тау итәгенә сыенып утырган, каршы яктагы тау битенә менеп карасаң, Түбән оч белән Югары очны иңләргә караш җитми. Аскы урамдагыларның бәрәңге бакчасы чал өянкеләр белән каймаланган инеш ярына килеп тоташа. Иң өске урамдагылар, без сездән киммени дигәндәй, тау башына кайчандыр яшь каен үсентеләре утырткан булганнар – инде алар да ипләп кенә картаеп килә. Бу төбәккә тәүге тапкыр аяк басучыны иң шаккатырганы – өске урамнан да югарырак урында, тау түбәсендә көзгедәй ялтырап утырган берсеннән-берсе кечкенә өч күлдер, мөгаен. Авыл аша үтеп киткәндә, инеш аша салынган күпердән чыгып, артына әйләнеп караган кеше дә, олы юлдан турыга гына кайтып төшкәндә – һәммәсе аһ итә: кульяулык-кульяулык булып күренгән күлләрнең әллә кайда югарыда, тау башында булуы нинди дер могҗиза булып тоела. Тагын да гаҗәбе – ул тирәдә яшәүчеләр, ишегалдында кое казыйм дип никадәр җәфаланса да, су табу бәхетенә ирешә алмыйлар. Урта урамдагылар исә язын базга су тулудан зарланып туялмый.

Гөлсәйдәнең авыл Сабан туена беренче тапкыр гына кайтуы түгел. Монда туган-тумачасы булмаса да, балачак дусты Асия йортында һәрчак көтелгән кунак ул, ире Сөләйман исән чагында да, сирәк кенә булса да кайткалап йөрделәр. Ул чакларда Асия дә пар канатлы, Разифы белән чөкердәшеп яшәп ята иде. Ирләр икесе дә гүр иясе инде, авыр туфраклары җиңел булсын.

Гөлсәйдәне, читтән кайткан олы кунагыбыз, авылдашыбыз дип, Сабан туенда президиумга утырттылар, хәлдән килгәнчә кунак иттеләр. Бәйрәмне алып баручы кыз аның турында җылы сүзләр әйтеп, шигырьләрен дә кычкырып укыды, аның сүзенә язылган җырны да башкардылар.

Үзе таныган, аны таныган авылдашлары берән-сәрән генә калып барса да, кочып күрешердәй, исәнлек сорашырдай кешеләр байтак иде. Гөлсәйдә бераздан мәйдан тирәсенә чыкты, елашып-көлешеп, авылдашлары белән күреште. Аннан, бәйрәм төгәлләнүгә таба барганда, Асия янына эскәмиягә килеп утырды. Шулвакыт аның артында кемнәрдер:

– Без дә гомер буе бил бөгеп эшләдек, күрүче дә, белүче дә юк, – дип, борын астыннан мыгырдаганы ишетелде. – Авылдан чыгып качкан кулак балаларын әле һаман күккә чөяләр, түргә утырталар!

Гөлсәйдә карчыкның тәне эсселе-суыклы булып китте. Әллә кайчан онытылган, инде беркемнең дә телендә калмады дип уйлаган сүз бөгерен хәнҗәр урынына телеп үтте. Ипләп кенә артына борылып карады. Үзеннән бер адым гына читтә гәүдәсе урталай бөгелгән, шәмәхә төстәге яулыгы астыннан ярты башы күренеп торган, карчыга борынлы, төссез күзле кортканы кемгә охшатырга да белмәде.

Авырткан билен угалап утырган Асия ахирәте, борылып та тормыйча:

– Кем булсын, теге оч Мәгъфия бит. Атасы Мирхәтне онытмасаң... – дип, терсәк очы белән төртеп куйды.

Онытырсың... Аны гына түгел, сугыш елларында олысы-кечесенең җелегенә төшкән бәндәләрне онытырлыкмы... Гомумән, үткәннәрне онытырлыкмы... Сугыш, кайчан гына, кайда гына, нинди генә суратта булмасын, ул кара кайгы гына алып килә. Ул адәм балаларының күңел канатын сындыра, бәгырен ташка әйләндерә. Сугыш – олысының да, кечесенең дә күз яшьләре белән генә түшәлә. Кешеләрне кансыз, мәрхәмәтсез, вөҗдансызга әверелдерә. Гомумән, яшәү өчен, ничек кенә булса да үз җанын саклап калу өчен көрәш кешеләрне акка-карага, яхшы-яманга бүленергә мәҗбүр итә. Берәүләр, чылбырдай тезелеп үткән торналарның канат кагышында яшәү җыры ишетеп, ак теләкләр теләп кул изи. Икенчеләр, бер җәй генә яшәп өлгергән тузганак керфекләрен каһкаһәле сулыш белән җилгә тарата-тарата, үзенең мәңгелек җан иясе икәненә инангандай, шул гөлләрдән ихахайлап көлә.

***

– Әткәйне корт чакты! – Гөлсәйдә еламсырап ишектән атылып кергәндә, Хәдичә ике кулына бияләй киеп, мич куеныннан чуен чүлмәк алып маташа иде. Кызының кисәк кычкыруыннан чүлмәген төшереп җибәрә язды, ярый әле өреле шулпа алъяпкыч итәгенә генә чәчрәде – тәки янып пешәсе иде.

– Котымны аласың бит! Нигә дөнья яңгыратып кычкырасың? – Тавышын күтәрми генә кызын битәрләгәндәй иткәч, Хәдичә елмаеп куйды. – Атаң мактана иде, мине гомердә дә корт чакканы юк дип, чират җиткән икән. Кая, салкын су булса да куйыйк... – Шулай дип сөйләнә-сөйләнә, яныңдагы агач кисмәктән ярты чүмеч су алды, шадра сөлгене эләктерде дә җитез адымнар белән ишегалдына ашыкты.

Әмирхан ян бакчада үзе утырткан алмагачы янында кайнаша иде, йөзе теше сызлаган кешенекедәй чытык. Хәдичә, елмаюын күрсәтмәскә тырышып, борчылган кыяфәт белән аңа кулындагы юеш сөлгене сузды.

– Нәрсәгә бу? – Әмирхан аптыраган кыяфәт белән хатынының күгелҗем күзләренә күтәрелеп карады.

– Корт чакты ди бит, шешеп чыкмасын дим.

– Ә-әй... – «Таптың сөйләр сүз» дигәндәй, ир кискен итеп кулын селтәде, иелеп, кечкенә көрәк белән агач төбе йомшартуын дәвам итте. Бераздан гына, йөзен ачмыйча: – Угын алдым – вәссәлам... Корт нәрсә ул, кешеләр чакса яман... – диде.

Әнисенең озын күлмәге артына посып торган Гөлсәйдә колакларын шомрайтты: менәтрәк, кеше дигәнең ничек чаксын инде... Әтисенең шул булыр, телендә гел табышмак. Шуңа микән, үзе укыткан бала-чага да ярата аны, Гөлсәйдәне көнләштереп, тирәсендә бөтерелеп кенә йөриләр.

– Атасы... – Хәдичә иренең сәбәпсез борчылмавын белеп, шомлана төште. Сүзен әйтеп бетермәде, кызына борылды. – Балам, бәбкәләргә үлән турап ал әле, яме, – дип, артындагы «озын колак»ны җайлап кына өйгә озатты. Аннан, көрчеккә терәлгәндәй, тагын тукталып калды. Иренең бөкрәя төшкән озын гәүдәсенә, киң җилкәләренә, маңгай турысыннан өскә кайтарылып торган дулкын чәчләренә сөеп тә, куркынып та карап куйды. – Бер-бер хәл булдымы әллә?

Әмирхан янә тиз генә җавап кайтарырга ашыкмады. Тураеп басты да инде эңгер эленеп килгән урамга койма өстеннән күз ташлады, нәрсәдәндер шикләнгәндәй, башын кыңгыр салып, тыңланып торды. Аннан:

– Иртүк районга төшеп җитәргә куштылар, – диде ишетелер-ишетелмәс кенә.

– Ай Аллам! – Хәдичәнең йөрәге урыныннан купты. Соңгы араларда иренең мәктәптән еш кына сүрән йөз белән кайтып керүе, артык җәелеп сөйләшмәве күңеленә торып-торып шом сала иде, тел тибрәтеп үзе сүз катмагач, артыгын төпченергә базмады. Авылдан әле бер, әле икенче кешенең районга «китткән» җирдән кире әйләнеп кайтмавы, кайберәүләрне төн уртасында «килеп үк алулары» халык телендә пышын-пышын гына сөйләнгән куркыныч вакыйгалар булып, болай да йөрәкне калтыратып кына тора иде. Шулай да ирен юатырга теләп: – Мәктәп эше белән чакыртулардыр, нигә аптырыйсың, – дигән булды, мәҗбүри генә елмаеп.

– Сәлам хаты язучылар табылган. Бригадир Мирхәт тырыша. – Әмирхан тагын күзен кыса төшеп, як-ягына каранды да, көрәген тотып, башын иеп кенә бакча капкасына таба юнәлде. – Өйгә керик булмаса.

– Сәетне ай күрде дә кояш алды, тагын уенга чыгып ычкынган. – Хәдичә, болдыр култыксасында улының күлмәген күреп, башын чайкап куйды. – Тәки шул гадәтен ташламый әй, шәрә тән чыгып йөгергән.

– Ярар, талкыма баланы, уйнап калсын. – Әти кешенең болай да сүрән йөзеннән күләгә йөгереп узды.

Өйгә кергәч, Хәдичә мич аралыгыннан комган белән сөлге алып чыкты, кечкенә таска агыза-агыза иренең кулына су салып торды. Агач курчагына гаҗиттән күлмәк ясап маташкан Гөлсәйдә артсыз урындыктан шуып кына төште дә мыштым гына ишегалдына чыгып сызды.

...Әмирхан районга төшсә дә, аны күрүче-ишетүче булмады: «Сугыш башланган!» дигән дәһшәтле сүз ул көнне дөньяның астын өскә китереп ташлаган иде.

Дәвамы бар >

Шигърият

Роберт ӘХМӘТҖАНОВ

***

Күпме булган инде хата гамәл,
кыен чәчеп, җиңел урганнар?!
Кергән һаман җанга җилбәзәкләр,
читтә калган көтеп торганнар.

Мәхәббәттә һәм нәфрәттә әле,
бу тормышта һаман өйрәнчек.
Узып китә гомер, – дошман түгел!
тик үз-үзең белән көрәшеп!

Феникстай, көлдән ярала рух,
хыялларның чиге күренми...
Шаулый җанда Идел тупыллары,
якты еллар хоры сүрелми!..

***

Кырларымда, әни, иминлекме,
агарамы борчак басулары?..
Тәрбелидә йөргән торналарым
кайтты микән быел? Барсы дамы?

Керләреңне, әни, җил аламы,
тәрәзәңдә миләш чайкаламы?
Каз үләнле чишмә сукмагына
чиләгеңнән сагыш чайпаламы?

Камылларга тулган зәңгәр таңмы,
кызардымы яфрак өрәңгедә?
Сибәлиме спас яңгырлары
Бәрәңгегә?!

Капкаң бик еш ачылып ябыламы,
коялымы һаман ишегалды?..
Эңгер төшкәч, карт-корылар гаме
биләп ала микән күрше тауны?..

Мин, тау чаклы сорау өеп, тагы
онытканмын, әни: үзең саумы?!
Иминлекме, әни, йөрәгеңдә?!

***

Нигә шигырь?
Тормыш шигырьдән дә
катлаулырак икән ләбаса.
Нигә мунча, нигә ләүкә сиңа,
төнлегеңдә йолдыз янмаса?

Нигә яздым шигырь?
Җанны сыгып, –
бу заманга шигырь – ни аңа?
Ходай үзе гарешләрдән сөргән
явыз кавем кайта дөньяга.

Без китәбез,
җырлый шовинистлар,
сатаналар килә –
өр-яңа!

ЭЛЕГИЯ

Җете иде әле гөлнең таҗы,
яшь йолдызым яшел болында.
Күңелемдә балкып калды назы,
җан җылысы янды кулымда.

Гөлләр белән болын бәхилләшә,
күбәләкләр китә энҗегә.
Шат йолдыздай яшьлек нурын чәчеп
китеп барды... бөтен гомергә!

Җиләс җилдә уйнап моңлы сазын,
сусәрдәләр инде кыйганнар...
Тузганаклар булып очты,
язын
чәчәк булып җиргә
кунганнар.

БЕЛМИ К@ЛМ@

@ – бу билге интернетта эшли белүче һәр кешегә таныш. Русларда аны «собачка» дип атыйлар. Ә татарча ничек атыйк икән? Эт? Кәчек? Сез уйлый торыгыз, ә без бу билгенең башка илләрдәге аталышын барлыйбыз.

Италия – **әкәм-төкәм**
Венгрия – **суалчан**
Әрмәнстан – **кәчек**
Германия – **маймыл**
Нидерланд – **маймыл койрыгы**
Дания – **фил борыны**
Тайвань – **тычкан**
Израиль – **штрудель**
Сербия – **кыргый «а»**
Вьетнам – **элгечле «а»**
Кытай – **чәчәк атучы «а»**

Әз-мәз мәзәк

Үзегезне 10 яшькә яшьрәк күрсәтәсегез килсә, яшегезне 15 елга арттырып әйтегез.

***

– Котлыйм, иптәшләр! Безнең фирма тандыр отты.
– Бәлки тендердыр?
– Юк.

***

Яр буенда комлыкта «Су коену тыела» дигән язуны күргәч кенә мин июль җиткәнен аңладым.

***

Балыкчының иң куркыныч төше: ул үлә, ә хатыны кармакларны ул әйткән бәядән сата башлый.

***

– Сиңа ничә яшь?
– Хатын-кызның яшен сорамыйлар.
– Алайса, авырлыгың күпме?
– Миңа 37 яшь.

***

Бу җәй салкын булса, хет ябыгасы булмас иде!

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Аксубай, Садыйкова, Данил, ылыс, йомгак, әсбап, мә, акбур, агач, ял, Лев, салам, иярчен, Спас, чалма, акыл, Бәйрәкә, талир, ир, уй, Лоун, Филя, Дим, тар, до, Ермак, ару, ярык, Хөсәенова, Наласа.

Вертикаль: абыстай, альманах, оялчан, Ту, Галимҗан, Кави, АиФ, йодрык, крикет, По, Убырлы, сандык, Лия, марҗа, әрсез, дары, Дилә, өс, Ан, Докукин, бал, бәби, ас, памперс, маис, куа, Алтынчәч, Хәйруллин.

Беләсең килсә...

1 Пломбир туңдырмасын кайсы илдә уйлап тапканнар?
а) АКШ;
б) Франция;
в) Канада.

2 Бу әдипләрнең кайсы романтизм жанрында иҗат иткән?
а) Достоевский;
б) Карамзин;
в) Лермонтов.

3 Менделеев таблицасында 50 нче элемент:
а) алтын;
б) тимер;
в) аккургаш.

4 The Sun британ басмасы әлеге спортчының финанс хәлен 5 миллион доллар дип бәяләде.
а) Алинә Заһитова;
б) Ләйсән Үтәшева;
в) Камилә Вәлиева.

Җаваплар: 1. б); 2. в); 3. в); 4. а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 299

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+